«Үз йөрәгең аша кичермәсәң, мәхәббәт турында язып булмый»

Шау чәчәкле язларда дөньяга аваз салгангамы, үзендә гомер буе шул язларның матурлыгын саклап калган ул. Әйтерсең бүген дә яшьлек иленнән китмәгән. Шагыйрә, язучы, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Флёра Тарханова шушы көннәрдә үзенең гомер бәйрәмен каршылый.

5 БИТ

Рамазан аеның фазыйләте

27 майда уразага керәчәкбез. Ислам динендә 12 айның иң зурысы булып Рамазан ае санала. Рамазан аеның башка айларга караганда өстенлеген ислам галимнәре ничек аңлата? Шушы айның хикмәтләре хакында «Өметләләр» мәчете имам хатыйбы Алмаз хәзрәт Сафин язмасыннан укыгыз.

8-9 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 26.05.2017 | № 56 (5818)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

УРМАНГА БЕРӘҮЛӘР – КҮМЕР, ИКЕНЧЕЛӘР СУ ТАШЫЙ

Озын-озак кышларда җәйне белеп сагынабыз. Җәй – җәннәт мисалы, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Кызганыч, без шушы фани дөнья «җәннәтен» саклый белмибез әле.

САК БУЛ!

Дамир БӘДРИЕВ

Автор фотолары

Татарстанда май бәйрәмнәрендә табигать кочагында сүндерми калдырылган учаклардан ут үрмәли башлауның 130 очрагы теркәлгән. Әлеге чыганаклар урман сакчылары тарафыннан үз вакытында сүндерелгән.

Урманнарда янгын башланган очракта, республиканың 87 торак пунктына, 82 балалар җәйге лагерена, 19 шифаханәгә, 29 бакчачылык ширкәтенә һәм 14 сәнәгать корылмасына турыдан-туры хәвеф яный.

– Урман яну ул – кешелек фаҗигасе. Янгыннарда яшеллек белән бергә тереклек дөньясына да зур зыян салына. Шөкер, соңгы алты елда республикада урманнар януына юл куелмады. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, республика хөкүмәте, Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы ярдәмендә, республикада урман янгыннарына каршы хезмәтнең матди-техник базасы нык яхшыртылды, – диде Татарстанның «Урман янгыннары үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Айрат Әхмәров.

Татарстанда урман янгыннарына каршы 23 янгын-химик станциясе булдырылган. Гомум коллектив 6015 кешене берләштерә, 1852 берәмлек техника файдаланыла. Айрат Әхмәров әйткәнчә, техниканың барысы да төзек. Әлеге теманың актуальлеген аңлап, журналистлар өчен «Биектау» янгын-химик станциясенә махсус сәфәр оештырылды.

– Безнең карамакта дүрт янгын сүндерү машинасы һәм башка кече техника бар. Күрше республикаларда һәм өлкәләрдә чыккан урман янгыннарын сүндерүдә дә катнашабыз. Иң мөһиме – коллектив бердәм, тәҗрибәле, – дип таныштырып үтте станция җитәкчесе Ленар Гобәйдуллин.

Баш механик Марат Рамазанов әйтмәсә дә, күз алдыбызда – парктагы техника берсеннән-берсе яңа.

– Татарстанда язгы якта урманнар читләрендәге 7 мең километр янгынга каршы ерым яңартылды, тагын яңа 3 мең километр ерым ясалды. Бу – болыннарда яки кырларда чыккан ут урманнарга күчмәсен өчен эшләнелә. Федераль трассада һәм республика әһәмиятендәге автомобиль юллары буйларына 265 яңа ял урыннары төзелде. Табигатьтә ял иткәннән соң, кешеләр учакларны ныклап сүндерсеннәр, корыган үләннәргә ут төртмәсеннәр иде, – дип үтенде Айрат Әхмәров.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 10 ноябрендә кабул иткән 1213нче карары буенча, авыл хуҗалыгы файдалануындагы җирләрдә, запастагы җирләрдә һәм кырларда камылны яки корыган үләнне яндыру, учак ягу тыелган. Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәмәсәң, Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 8.32нче маддәсе нигезендә, гражданнарга – 5 мең сумга, җитәкчеләргә – 50 мең сумга, юридик затларга 1 миллион сумга кадәр штраф салына.

Урманнарда, кырларда һәм болыннарда янгын башлануны күрсәгез, түбәндәге телефоннар аша хәбәр бирегез: төбәк диспетчерлык идарәсе пункты: **8(843) 221-37-95;** урман саклауның туры элемтәсе: **8-800-100-94-00**. Элемтә тәүлек дәвамында гамәлдә, шалтырату бушлай.

Дмитрий Медведев – Казанда

Кичә Россия премьер-министры Дмитрий Медведев Казанга ике көнлек эш сәфәре белән килде. Ул башкалада уза торган икътисадны модернизацияләү буенча Совет президиумы утырышында катнашачак. Әлеге чарада икътисадта университеттагы эшмәкәрлекнең тоткан урыны һәм студентларның технология эшмәкәрлеге үсеше хакында сөйләшәчәкләр.

Утырышка кадәр премьер-министр Казан федераль университетының яшь галимнәре белән очрашты. Бу егет-кызлар фән өлкәсендә югары технологияләр кулланып эшлиләр.

– Сезнең университет – данлыклы. Бөтен югары уку йортларын дөньякүләм дәрәҗәдәге бер зур, классик университетка туплау дөрес карар булган, – диде Дмитрий Медведев.

Ул яшь галимнәргә фәнни эш белән шөгыльләнү өчен бүлмәләр арендалау процессын җиңеләйтергә кушты.

Бүген – 26 майда, Россия премьер-министры Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге хөкүмәте башлыклары һәм Евразия хөкүмәтара советы утырышларында катнашачак.

Россия Президенты Владимир Путин Мәскәү Кремлендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановны Александр Невский ордены белән бүләкләгән. Республика Президент сайтының матбугат үзәге хәбәр иткәнчә, әлеге югары дәрәҗәдәге бүләк «дәүләт алдындагы казанышлар һәм Россиядә халыкара абруйны ныгытуга зур өлеш керткән өчен» бирелгән.

Рөстәм Миңнеханов орденлы булды

Тарихтан билгеле булганча, Александр Невский ордены Екатерина I вакытында ук барлыкка килгән. 1942 елдан СССРда бу орден белән Кызыл Армия командирларын бүләкләгәннәр. 2010 елдан ул орден – дәүләт бүләкләре исемлегендә. Александр Невский ордены ияләре арасында дөньяда беренче хатын-кыз космонавт Валентина Терешкова, Россия Саклык банкы Президенты Герман Греф, Россиянең оборона министры Сергей Шойгу һәм башка билгеле шәхесләр бар. Былтыр бу бүләк Кыргызстан Президенты Алмазбек Атамбаевка тапшырылган иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Соңгы кыңгырау чыңы

Бу көннәрдә Татарстан мәктәпләрендә соңгы кыңгыраулар чыңлый. Башкала укучылары әлеге күңелле дә, моңсу да булган бәйрәмне 23 майда билгеләп узганнар иде. Казан мәгариф идарәсеннән хәбәр итүләренчә, башкала мәктәпләрен быел 5313 укучы тәмамлый. Аларның 586сы алтын медальгә дәгъва итә.

Әкичә кыңгыраулар республика районнарындагы чыгарылыш сыйныф укучылары өчен чыңлады. Быел Татарстанның 15 меңнән артык егет һәм кызы – XI, ә 34 471е IX сыйныфны тәмамлый. Күңелле бәйрәмнәр төгәлләнгәч, укучыларны зур сынаулар каршы алачак. Бүген алар өчен Бердәм дәүләт имтиханы бирү кампаниясе башлана. Беренче имтиханны укучылар инглиз теленнән тапшырачаклар. Соңгы имтихан исә 1 июльгә билгеләнгән.

Иртәгә уразага керәбез

Быел Рамазан аенда, элеккеге еллардагыча, мәчетләрдә ифтар ашлары узачак. Узган ел 30 мәчет көн дә ифтар ашы оештырган. 23 мәчеттә Рамазан ае дәвамында Корьәнне башыннан ахырына кадәр укып чыгачаклар. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин әйтүенчә, быел да ураза аенда әлеге традицияләр дәвам иттереләчәк. Төркиядән республика мәчетләренә Коръән хафизлар киләчәк.

– Иртәгә алар килеп тә җитәчәк. Барысы 38 Коръән хафиз килергә теләк белдерде. Берничәсе Казанда калып, калганнары районнарга китәчәк, – дип сөйләде журналистларга Камил хәзрәт.

Мөфти бүген беренче тәравих намазы укылачагын да хәбәр итте. 27 майда исә уразага керәчәкбез. Камил хәзрәт әйтүенчә, быел фитыр сәдакасының күләме 100-600 сум. Һәркем үзенең байлыгына карап бирәчәк. Зәкят түләү өчен нисаб күләме 198 000 сум дип билгеләнгән. Шуның кадәр акчасы булган кеше бай санала, диде мөфти.

Матбугат очрашуында катнашкан мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин сүзләренчә, ураза ул нәфесне дә тәрбияли.

– Аллаһы Тәгалә ураза аркылы кешеләрнең җаннарын һәм тәннәрен тәрбияли. Сәхәрне кайда, ифтарны кайда ашыйм икән дип баш ватып йөрергә кирәкми. Күпләр өендә әзерләгән ифтарда чикне белеп ашый, мәҗлескә барып күп итеп сыйланып кайта да ашказаны авырта башлый. Нәфесне тыя белергә кирәк. Аннары күп кенә мөселманнар Рамазанга кадәр үк атнасына бер-ике көн ураза тота башлады. Бу организмга тиз җайлашырга булыша, – дип сөйләде ул.

Сүз уңаеннан: 1 июньнән, Рамазан ае башлануга туры китереп, Татарстанда «Мөхәммәд – Аллаһ илчесе» фильмы прокатка чыга. Кинотасмада Мөхәммәд Пәйгамбәрнең балачагы чагылыш тапкан, дип яза «Татар-информ». Татарстан Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү буенча тикшеренүләр үзәгенең әйдәп баручы эксперты Рөстәм Батров фикеренчә, өч сәгатьлек картина бер тында карала. Фильмның режиссеры Мәҗит Мәҗиди кинотасманы җиде ел төшергән. Шуның өч елын ул белгечләр белән фикер алышуга багышлаган.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

60 ел бергә гомер иткән парларны тәбрикләделәр

«Казан» гаилә үзәге, Казан шәһәре мэриясе белән берлектә, 50, 60 ел бергә яшәгән парларны тәбрикләде. Үрнәк гаиләләргә Казан шәһәре Думасы депутаты Раушания Бильгильдеева мэр исеменнән акчалата бүләк тапшырды һәм котлау сүзләре җиткерде.

– Без ай саен диярлек Казанның озак еллар бергә яшәгән үрнәк парларын тәбриклибез. Бу традиция 2001 елдан бирле яшәп килә. Мондый чаралар уздыру бик мөһим. Озак яшәүче парлар ихласлыкны, гаилә кыйммәтләрен саклап кала алганнар, җылы хисләрне балаларына, оныкларына, оныкчыкларына күчергәннәр. Алар безнең шәһәребезнең горурлыгы. ЗАГСларның төп максаты – документ эшләрен башкару гына түгел, без гаиләне саклап калуга зур игътибар бирәбез, – ди «Казан» гаилә үзәгендә чаралар оештыру бүлегенең җитәкчесе Гөлнара Хафизова.

Бу юлы 11 гаиләне тәбрикләделәр. Һәрберсенең йөзендә – шатлыклы елмаю, бер-берсенә карата хөрмәт, ярату. Язмыш аларны кайда гына таныштырмаган: Архиповлар – төзелештә, Вахитовлар – медицина институты ашханәсендә, Куликлар Офицерлар йортында кичке биюдә танышканнар. Шуннан бирле иңне-иңгә куеп, дистә еллар бергә яшәргә насыйп булган. Бүген алар – яраткан дәү әти белән дәү әни. Юбилярларны котларга балалары, оныклары, оныкчыклары да килгән иде. Ахырдан, барысы да җыелышып, «Татмедиа» бинасы янында агачлар утырттылар.

Сүз уңаеннан, ЗАГС органнары оешканга быел – 100 ел. Шул уңайдан чаралар тынып тормый. 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көнендә «Казан» гаилә үзәге каршында бәйрәм оештырырга уйлыйлар. 8 июль – Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көненә багышлап та зур чара әзерләнә.

Эльвира ГЫЙСМӘТУЛЛИНА.

Яман шешне җиңгән Лилия Кох:

«Авырмыйм дип яшәдем»

Еш кына яман шеш диагнозы куелган кешеләргә кызганып карау гадәтләнгән. «Мондый авыруларны туганнары, якыннары тормыштан сызып ук ташлыйлар. Тик кешенең куркуы – мәгълүмат аз булудан. Кеше рактан башка яшәргә өйрәнергә тиеш», – ди психолог, лайф-коуч Лилия Кох.

Эльвира МОЗАФФАР

Ул бу авыру турында ишетеп кенә сөйләми. Үзе яман шешне җиңгән. Дәвалану барышында язып барган көндәлекләреннән «Үлем белән яшәү арасында 100 көн» дип исемләнгән китап бастырган. Хәзер төрле чит илләрдә – Германия, Америка Кушма Штатлары, Гарәп Әмирлекләрендә пациентлар белән тернәкләнү курслары уздыра. Дәвалау алымы да гадәти түгел – «Феникс-яңарыш» дигән гадәти булмаган психологик уен уйлап тапкан. Сүз уңаеннан, бу уен Республика клиник онкология диспансерында дәваланучыларга да тәкъдим ителәчәк. Бу хакта «Татар-информ»да узган матбугат конференциясендә сөйләделәр.

– Китап язам дип уйламаган идем. Россиядән чит илгә күчеп киткәч авырый башладым. Барысы да борчылулар аркасында дип уйлыйм. Теләсә кайсы авыруны да стресс китереп чыгара бит. Үземдә 3-4нче стадиядәге яман шеш икәнлеген белгәч тә, төшенкелеккә бирелмәдем. Минем авырырга вакытым юк, тормышка ашырасы планнарым күп, мин авырмыйм, дип яшәдем. Мөгаен, үз-үземә ышаныч авыруны җиңәргә ярдәм иткәндер дә, – дип сөйли Лилия Кох.

Дәвалану барышында ул көн саен көндәлек алып барган. Язмаларны үзенең блогында бастырган. Укучылары вакыйгаларның дәвамын сорый, бу хикәятләрнең ярдәмен тоя башлагач, Лилиягә китап бастырырга тәкъдим иткәннәр. Шулай «Феникс-яңарыш» уены да туган. Бу уен үз-үзеңне табарга, үзеңдә ышаныч тоярга ярдәм итә.

– Яман шеш диагнозы куелган кешеләргә авыру белән яшәргә ярамый. Онытылып торырга, башка кызыксынуларны булдырырга кирәк. Бу уенның максаты да шунда. Ул авырулар өчен генә түгел, яңа тормыш башларга теләгән һәркем өчен файдалы, – ди Лилия.

Онкология авырулары бүген медицина өлкәсендә төп мәсьәләләрнең берсе. Былтыр Татарстанда яман шеш белән авыручыларны тернәкләндерү өлкәсенә аеруча зур игътибар бирү бурычы куелган иде. Бу максатларда Республика онкология диспансерында тернәкләндерү бүлеге дә ачылды. Койкалар җитми башлагач, шәхси партнерлар белән хезмәттәшлек итүгә күчтеләр.

– Шул рәвешле Константиновка бистәсендә тернәкләндерү клиникасы барлыкка килде. Дөрес, әлегә анда 50 кеше генә дәвалана ала. Киләчәктә койкалар санын арттырырга уйлыйбыз. Биредә дәвалану бушлай, – дип клиника эше белән таныштырды Республика клиник онкология диспансерында оештыру-методик эш буенча баш табибның урынбасары Булат Мәҗитов.

Бүген Татарстанда онкология авыруларыннан дәваланган 90 меңгә якын кеше исәпләнә.

Автор фотосы

«Рәхмәт Наил абыйга!»

Әтнә районы Дусым авылы урамы буйлап барабыз. Юлларга асфальт түшәлгән, ике яклап ямьяшел чирәм, койма башларыннан шау чәчәктә утырган шомырт агачлары үрелеп карап кала. Матур, бик матур. Авылларның урамнарындагы юллар тәзек булса, йортлар да ничектер күркәмрәк булып китә. Халык үзе дә капка төпләрен чистартып, гөлләр, куаклар үстерә башлый. Моннан берничә ел элек Дусым авылында булырга туры килгән иде, ул вакытта юллар әллә ни мактанырлык түгел иде дип истә калган. Авыл халкыннан «Юлларыгызны кайчан салдыгыз, үзара салым акчасынамы, берәр программага эләктегезме?» – дип кызыксынам.

– Рәхмәт Наил абыйга! Безнең Наилебез бар!

Кемнән генә сорама, җавап бер булды. Республикада билгеле шәхес Наил Сабиров безнең редакциябезнең дә якын дусты, без аны күп еллардан бирле беләбез. Шуңа күрә аның турында әйтелгән яхшы сүз йөрәккә май булып ятты.

Наил абый Сабиров тумышы белән Дусымнан. Туган туфракны ничек итеп яратып була дигәндә, Наил абыйны өлге итеп күрсәтергә кирәктер. Аның яратуы – кайгыртучанлык, чын йөрәктән башкарылган бик күп игелекле эшләр. Үзе Арчада яшәсә дә, Дусымга даими кайтып, андагы бөтен эшләр белән кызыксынып, үзенең төпле киңәшләрен биреп тора. Иң мөһиме, әлбәттә, авылдашларының күңелләрендәге мәңге шундый эчкерсез рәхмәт, олы ихтирам булу.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

«Анда да газетагызны рекламалыйсыңмы әллә?»

Дубайга баруыбыз, бу илдәге гүзәллек турында язган идем инде. Хаклы рәвештә дөнья җәннәте дип аталган әлеге илнең төрле җирләрендә истәлеккә төшкән фоторәсемнәрне өйдә калганнарга ватсап (вәт шәп!) аша җибәреп тордык. Ак киемле гарәпләр (мин аларны шәехләр дип атадым) белән төшкәнендә кулымда гәҗит иде. Гомеремне шул эшкә багышлагач, гәҗит күргәч, гарәп телендә булганга, укып аңламасам да, янынннан үтеп китә алмадым, алдым. Без студент чакта гарәп газеталарын аз тәрҗемә итмәдек үзе: хәрефенә кадәр күңелгә якын булып кереп калган, яшьлекне хәтерләтә. Шул гәҗитне тотып, бергәләп сурәткә төшәргә рөхсәт сораган идем, рәхмәт инде, риза булдылар. Өч шәех янына басып төштем сурәткә, ирем төшерде. Шуны өйдәгеләргә җибәргән идек, минем телдән гомер буе подписка төшмәгәнен белеп-күреп үскән улларым: «Әни, син анда да газетаны рекламалап йөрисеңме әллә?» – дигән җавап җибәрделәр. Көлдек рәхәтләнеп. Әйе, ул Дубай байлары матбугатының иганәчеләре булса, шәп булыр иде дә бит, кана, татар матбугатының бер проблемасы да калмас иде. Кая инде безгә андый бәхетләр. Яннарына басып фотога төшәргә рөхсәт иткәннәре өчен дә рәхмәт.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Татарстан авылларында республика мәдәни марафонын Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле Саба районының Лесхоз бистәсендә башлап җибәрде. Әлеге проект Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды ярдәме белән оештырылды. Концертлар Президентның махсус программасы нигезендә төзекләндерелгән авыл мәдәният йортларында уза. Катнашучы җырчыларның күбесе үзләре дә авылда туып-үскән. Татарстанның атказанган артисты Фәрит Гафиатуллин озак еллар ансамбльдә эшли.

Авылларда – мәдәни марафон

– Без үзебез дә әбиләребез, әниләребезнең моңлы итеп халык җырларын башкаруын тыңлап үстек. Мондый концертлар күбрәк тә булырга тиеш, чөнки авыл тамашачысын да профессиональ яктан тәрбияләргә кирәк. Тере тавыш белән җырлаганны халык әйбәт кабул итә, – ди ул.

Концертта ансамбльнең элекке солистлары Нәфисә Васильева, Таһир Якупов, Мәҗип Садыйков репертуарыннан җырлар яңгырады. Тамашачы төрле биюләр, хореографик күренешләрне яратып кабул итте.

Соңыннан ТР Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды башкарма директоры Нурия Һашимова дәүләт ансамбленең мәдәни марафон кысаларында чыгышлары дәвам итәчәген җиткерде. Ул тамашачыга Президентның: «Авыл мәдәният йортларында һәрвакыт бәйрәм булырга тиеш. Авылларда яшәүчеләр, хезмәтчәннәр мәдәният өлкәсенең иң яхшы уңышларын эре шәһәрләрдә яшәүчеләр кебек үк күрергә тиеш», – дигән сүзләрен ирештерде.

Люция ГАЛИМҖАНОВА.

МИЛЛИЯТ

«Татарстанда үзебезне өйдәге кебек хис итәбез»

Татарстанга чит илләрдән килеп укучы студентларның саны арта бара. Әйтик, 2012 елда аларның саны 3,5 мең булса, бүгенге көндә республика югары уку йортларында 10 мең студент белем ала. Аларның күбесе актив иҗтимагый тормыш белән кайный. Шундыйларның берсе – Төрекмәнстанның Туркменаба́д шәһәреннән килгән Джумагуль Ачылова. Ул Татарстанның чит ил аспирантлары һәм студентлары ассоциациясен җитәкли.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Югары белемне Россиядә алырга уйлаганнан соң, уку йортларын сайлый башладым. Эзләнә торгач, Мәскәү, Волгоград һәм Казан шәһәрләренә тукталдым. Шуларның өчесе арасыннан Казанны сайладым. Казан илкүләм тикшеренү техник университетында укыдым, хәзер аспирантурада белем алам. Студентлар тормышында актив катнашуымны күреп, чит ил аспирантлары һәм студентлары ассоциациясен җитәкләргә чакырдылар. Казан миңа бик ошый. Биредә мөселманнар күп. Урта Азиядән килүчеләр өчен бу бигрәк тә мөһим. Менталитетыбыз, гореф-гадәтләребез дә уртак. Милләтара мөнәсәбәтләр ягыннан караганда, республикадагы вазгыять тыныч. Монда милли сәясәт яхшы оештырылган. Чит ил студентына, үзенең проектын гамәлгә ашыру өчен, грантлар да бирелә. Халыклар дуслыгы йортында һәр милләтнең үзенең бәйрәмен уздыру мөмкинлеге бар. Анда концертлар да еш оештырыла. Аларны караганнан соң, үземне үз илемдә булган кебек тойдым дип, рәхмәтләрен җиткерәләр, – дип сөйли ул.

Ассоциация Казанның югары уку йортларында белем алучы чит ил студентларын һәм аспирантларны берләштерә.

– Чит ил студентларына социальләшергә, адаптация чорында ярдәм итәбез. Читтән килеп белем алучыларны борчыган мәсьәләләрне чишәргә булышабыз. Аларның бигрәк тә тел һәм мәдәният мохитенә җайлашу, Россия җәмгыятенең хокукый аспектларын аңламау, кайбер көнкүреш мәсьәләләре җитәрлек. Безнең ишекләр студентлар өчен һәрчак ачык. Уку йортлары белән хезмәттәшлек итәбез. Беренче курска укырга килүчеләрнең исемлеген булдырып, аларны төркемнәргә бүләбез һәм кураторлар да билгелибез. Кураторлар арасында җирле студентлар да, чит илләрдән килеп югарырак курсларда укучылар да бар. Алар яңа килгән студентларны шәһәр белән таныштыра, рус телен өйрәнергә ярдәм итә, – ди Джумагуль.

Чит ил студентларының ялларын кызыклы итеп оештыру өстендә дә эшлиләр. Мәдәни, спорт чаралары да уздыралар. Фәнни конференция, форумнар, конкурсларда актив катнашалар. Бүген шулай ук алар катнашында «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Дөнья мәрҗәне – 2017» матурлык бәйгесе узачак. Конкурс җитәкчесе Гүзәл Насыйрова безгә сөйләгәнчә, бәйге быел сигезенче тапкыр уза. Татарстанның чит ил аспирантлары һәм студентлары ассоциациясе инициативасы белән үткәрелә башлаган чараны оештыруда хәзер Казанның балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, Татарстанның Яшьләр ассамблеясы һәм Казан илкүләм тикшеренү техник университеты да катнаша.

– Быел конкурста катнашучы кызлар 14 илне тәкъдим итәчәк. Бәйрәмгә килүчеләр Казахстан, Кытай, Кыргызстан, Һиндстан, Төрекмәнстан, Вьетнам, Таҗикстан, Әрмәнстан, Бенин, Камерун, Польша һәм Россия, Дагыстан, Татарстанда яшәүче халыкларның традицияләре, костюмнары белән таныша алачак. Чарага дөньяның 30 иленнән 1000гә якын студент чакырылды. Без бигрәк тә җирле студентларны чакырырга тырыштык. Аларны чит илләрдән килгән курсташлары белән якыннан таныштырасыбыз килә. Без бер-беребез турында яхшырак белергә, бер-беребезне хөрмәт итәргә тиеш. Конкурста катнашачак кызлар да аңа әзерлек барышында үзара дуслашып беттеләр. Безнең беренче максатыбыз да шул. Чит илдән килгән яшьләр Татарстанны тиз арада үз итте. Мин үзем Үзбәкстанның Навои шәһәреннән килдем. Әтием – үзбәк, әнием татар милләтеннән. Әбием тумышы белән Татарстаннан. Бирегә татар мәдәнияте белән якыннанрак танышырга дип килдем. Монда килүемә бер дә үкенмим, үземне өемдә кебек хис итәм. Читкә киткәч тә Казанны сагына башлыйм. Казанда ярдәмчел, ягымлы кешеләр яши, – ди ул.

Аду Яо Никэз, Россиянең чит ил студентлары ассоциациясе Президенты:

– Татарстанда чит ил студентлары белән алып барыла торган эшчәнлекне югары бәялим. Аны Россиядәге барлык төбәкләр өчен үрнәк итеп китерәм.

Экологиядә дә бәхәскә урын бар

Бүген «Сәләт» йортында татар телендә уза торган «Безнең заман» III Республика дебатлар лигасы финалистлары Татарстан Республикасының экология һәм табигый байлыклар министры Фәрит Абдулганиев белән очрашты.

«Безнең заман» дебатлар лигасы – ел дәвамында уздырыла торган ярыш. «Сәләт» йортында татарча бәхәсләр инде өченче ел бара. Биредә мәктәп балалары, студентлар чыгыш ясау осталыгында ярыша. Әлбәттә, монда аудитория алдында оста аралашу сәләте генә сыналмый. Әтөрле өлкәләрне белү, эрудиция, гыйлем көче, үз фикереңне дәлилләп җиткерү сәләте дә кирәк.

Укучыларны кызыксындырган беренче сорау чүп ташлау темасы иде. Алар да яз көне кар астыннан чыккан чүпне игътибарсыз калдырмаган.

– Атнасына ике тапкыр республика территориясен һавадан тикшерәбез. Шунда шаккатам, чүпләр юл кырыенда да, ерганакларда да түгел, ә чип-чиста, матур болын уртасында җәелеп ята. Анда чүпне ташлар өчен никадәр барырга да кирәк бит әле. Районнарның экологик халәтен дә күзәтәбез. Аларның чисталыгы күбрәк җитәкчеләрдән тора. Иң чиста районнар – Казан артында. Әлмәттә чүплек, ачыклану белән, бетерелә. Безнең халыкта экологик үзаң өлгермәгән әле, – ди Фәрит Абдулганиев.

Әлбәттә, сөйләшү экология темасы тирәсендә генә бармады. Балалар министрдан лидерлык серләрен, борчыган экологик мәсьәләләр, чишелмәгән проблемалар турында да сорашты. Фәрит Абдулганиев үзе дә дебатларда ишетергә теләгән темаларын билгеләде. Шуларның берсе – хуҗалыклардагы тирес утильләштерү мәсьәләсе.

– Безнең дә дебатларга куелырдай бәхәсле проблемаларыбыз бар. Мәсәлән, авыл җирендә яшәүче кеше мал тиресен кая чыгарырга тиеш. Ул аны авыл читенә илтеп түгә. Без моның өчен 200 мең сум штраф салырга тиеш. Ләкин бу бит хуҗалыкның бер еллык кереме. Шул рәвешле авыл хуҗалыгына авырлык китерәбез. Бу ике яклы фикер тудыра, – диде министр, яңа темага оеткы салып.

«Безнең фикер» финалистларының ел саен республика лидерлары белән очрашуы үзе бер күркәм гадәткә әйләнде инде. Узган ел алар Татарстанның Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова белән очрашкан иде.

Алисә САБИРОВА.

Яңа һәм кулланышта булган металл (пенал) гаражлар сатабыз. Теләсә нинди үлчәмдә.
Китереп бирү бушлай. Бәясе 27 мең сумнан башлана. Тел.: 8-800-700-90-91
Реклама

«Үз йөрәгең аша кичермәсәң, мәхәббәт турында язып булмый»

Шау чәчәкле язларда дөньяга аваз салгангамы, үзендә гомер буе шул язларның матурлыгын саклап калган ул. Әйтерсең бүген дә яшьлек иленнән китмәгән. Шагыйрә, язучы, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Флёра Тарханова шушы көннәрдә үзенең гомер бәйрәмен каршылый. Шул уңайдан без аны кунакка чакырдык.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Флёра ханым, шагыйрьләр, язучылар, гадәттә, яшьтән каләм тибрәтә башлый. Сез әдәбият мәйданына соңрак килсәгез дә, шактый уңышларга ирешкәнсез, 26 китабыгыз дөнья күргән.

– Шуңа өстәп, 80 җыр иҗат ителде. Кайберләренең көйләрен дә үзем яздым. Мин балачактан ук җөмләләрне рифмалаштырып сөйләшергә яраттым. Шигырьләр мәктәптә, педучилищеда укыганда, «Радиоприбор» заводында инженер-конструктор булып эшләгәндә язылды. Язган шигырьләрем, хикәяләрем, публицистик язмаларым «Татарстан хәбәрләре», «Шәһри Казан» газеталарында эшли башлагач кына дөнья күрде. Шигырь язу безнең гаилә өчен ят нәрсә түгел. Әни дә, әби дә шигырьләр язган. Әтинең бертуган Нурулла исемле абыйсы пьесалар язып, авыл яшьләре белән бергә уйнаган. Хәтта күренекле нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыповны да беренче мәртәбә ул сәхнәгә менгергән.

– Үзегезнең дә «Әкият» Татар дәүләт курчак театрында «Өч каурый» әкиятегез куелганын беләбез. Балалар өчен бик матур шигырьләр җыентыгыгыз басылып чыкты. Нәниләр өчен язарга нәрсә этәрде?

– Әле дә хәтеремдә: бала чакта әти безгә әкиятләр сөйләргә яратты. Шул әкиятләрне минем хәзерге заман балаларына да җиткерәсем килде. «Өч каурый әкияте» – шигъри формада.

– Сезнең шигырьләр хатын-кызлар гына тоя, кичерә торган кайнар хисләр белән язылган. Әйтерсең аларга үзегезнең кичерешләр салынган.

– Ул хисләрне язучы яисә шагыйрь үз йөрәге аша кичермәсә, мәхәббәт лирикасын язып булмый торгандыр. Сөю хисе кайнар булганда гына матур шигырьләр туарга мөмкин.

– Милли хисләр белән сугарылган шигырьләрегезне дә очрашуларда, кичәләрдә укырга яратасыз.

– Татар халкы, тел һәм милли моңнар турында язган шигырьләрем шактый. Күптән түгел генә татарлар турында гимн язасым килде. Һәм без аны композитор Резеда Ахиярова белән иҗат иттек. Ул гимн юбилеема багышланган иҗат кичәмдә башкарылачак.

– Сезнең китапларыгыз ни өчендер китап киштәләрендә күренми.

– Әйе, үземә шалтыратып та ул хакта сорыйлар. Аларның сатылып бетүенә куанам гына. Җәй айларында күп кенә шигырьләр тупланган җыентыгым чыгарга тиеш.

– Министрлар Кабинеты аппаратында тәрҗемәче булып эшләдегез. Ул хезмәт тә теләсә кемнең кулыннан килми. Гомумән, тәрҗемә ничек җәлеп итте үзегезне?

– Бала чакта ук татар җырларын русчага тәрҗемә итеп җырлап йөри торган гадәтем бар иде. Педучилище тәмамлап, Кыргызстанның Ош шәһәренә киткәч, рус мәктәбендә – математика, үзбәк мәктәбендә рус теле укытырга туры килде. Шунда әкиятләр, хикәяләр тәрҗемә итә башладым. Аннары тәрҗемә белән университетта укыганда шөгыльләндем. Кандидатлык диссертациям дә тәрҗемәгә багышланган иде. Шуннан бирле тәрҗемә эшеннән аерылганым юк. Казакъ язучысы Рахимжан Отарбаевның Чыңгыз ханның күз яше китабын тәрҗемә итеп, Казанда бастырганнан соң, китапханәләргә таратылды. Китапны бик ошаттылар. Казакъстанга аны тәкъдим итү кичәсенә чакырып зурладылар да әле.

– Соңгы вакыттагы тәрҗемәләрегезнең берсе узган ел Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» китабы булды. Аның турында матбугат битләрендә шактый гына бәхәсләр дә барды. Сез алар белән килештегезме?

– Тәнкыйть фикерләрен мин кабул итмәдем. Тәнкыйть чынбарлыкка туры килмәде. Әле әсәрне тәрҗемә иткәндә, автор белән килештереп, аның кайбер урыннарын үзгәртергә туры килде. Шуңа күрә ул авторлаштырылган тәрҗемә дип атала. Ике ай эчендә 512 битлек әсәрне тәрҗемә итү җиңел эш түгел. Өч-дүрт ай дигәндә, басылып та чыкты, сатылып та бетте ул. Димәк, әсәр укучыларны кызыксындырган.

– Аны быел Уфада Гафури исемендәге башкорт драма театры куярга җыенуын ничек кабул иттегез?

– Әгәр рус варианты белән куйсалар, ул дөрес булмаска мөмкин. Төзәтелгәнен сәхнәләштерергә кирәк. Ул хакта Гүзәл Яхинага да әйттем. Аннары әсәр режиссерның ничек куюына да бәйле.

– Сез үзегез дә сәнгать яратучы кеше. Оста итеп җырлыйсыз, бисез. Сәхнә кешесе булсагыз да, уңышларга ирешкән булыр идегез. Туганнарыгыз арасында сәнгатьне үз иткән кешеләр дә бар.

– Безгә сәнгатьне яратып үсми мөмкин түгел иде. Чөнки әни бик матур җырлады, әти байтак уен коралында уйнады, мәктәптә кызларны – мандолинада, ә малайларны баянда уйнарга өйрәтте. Училищеда фортепьянога өйрәттеләр. Мәктәп елларында кино артисты буласым килгән иде. Әмма тора-бара артист һөнәренә мөнәсәбәтем үзгәрде. Безнең гаиләдәге тугыз баладан алты ир-егетнең һәркайсы баянда уйный. Җыр-музыка һәрберебезгә якын. Энем Илдусның минем сүзләргә үзе язган бик матур көйләре дә бар.

– Бөтен яктан да килгән кешедән «Нигә ялгыз калдыгыз?» дип сораучылар да бардыр...

– Андыйларга: «Үземә тиң кешене очратмаганга», – дип җавап бирәм. Күңелемә ятмаган кешегә кияүгә чыгу турында уйламадым да. Олыгаеп барсам да, әле гыйшык тотып йөрүчеләр бар.

– Гомер агышлары куркытамы?

– Юк, куркытмый. Әле эшлисе эшләрем күп. Аларны башкармыйча, беркая да китмим. Аллаһы Тәгалә сәламәтлектән генә аермасын, көч-дәрманны, бәхет-шатлыкны өстәп кенә торсын иде.

Китап фестивале – гаиләләр өчен

10-11 июньда «Черек күл» паркында җәйге китап фестивале узачак.

Биредә гаиләләр өчен төрле чаралар үткәрү программасы планлаштырылган. 3 яшьтән 12 яшькә кадәр булган балалар өчен остаханәләрне төрле нәшриятлар оештыра. Гаилә аттракционында катнашучылар үзләре персонажлар уйлап табып, аларга исемнәр кушалар һәм бер-берсенеке белән таныштыралар. Балалар көндәлек тормыштагы вакыйгаларны сюжет итеп алырга мөмкин. Ике көндә дә паркта музыкаль студия һәм фәнни-популяр лаборатория эшләячәк.

Китап фестивалендә балалар һәм үсмерләр өчен китаплар тәкъдим ителә.

Сөенечебез бар

Балачак курчаклы, машиналы, компьютерлы, телефонлы гына түгел, китаплы да булырга тиеш. Бүгенге заман баласының китапка бик әллә ни исе китми, эреле-ваклы экраннар белән дуслашуны кулайрак күрә. Ләкин без, балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр, баланың киләчәктә чын кеше булып үсүе өчен китапларның нинди зур әһәмияткә ия булуын яхшы беләбез. Шуңа күрә үзебезнең бакча нәниләрен китап дигән хәзинәгә якынайту өчен, төрле юллар эзләп табабыз. Күптән түгел бакчабызда, кечкенә булса да, китапханә оештырып җибәрдек. Ул барлык милләт балаларының да яраткан шагыйрәсе Агния Бартоның 100 еллыгына багышлап оештырылды. Китапханәне ачканчы, әти-әниләр һәм балалар белән шактый эшләр башкардык, шагыйрә иҗатына багышлап, әдәби-музыкаль кичә уздырдык. Максатыбыз шагыйрәнең кызыклы һәм тәрбияви шигырьләре аша балаларны һәм алар янәшәсендәге өлкәннәрне дә китапны яратырга өйрәтү, олыда да, кечедә дә укуга мәхәббәт тәрбияләү иде. Шул максатны тормышка ашыру өчен, без бакчабызның методик кабинетында китаплар белән тулы берничә киштә булдырдык. Дөрес, бездә әти-әниләр сораган, аларга кирәк китапларның барысы да юк. Ләкин аларны эзләп табып бирергә тырышабыз, күп вакыт өйдән дә алып киләбез. Нәтиҗәләр дә сөендерерлек. Китаплар куелган әлеге почмак бакчабыз балаларының иң яраткан урынына әйләнеп бара, тәрбиячеләре белән бергә кереп, Белем дөньясында сәяхәттә булып кайталар. Тукай туган көндә нәниләр Шүрәле һәм Су анасы белән таныштылар. Һәр төркемнең үзенең «укучы формулярлары» бар, укылган китаплар шунда язылып бара. Китапханәдән әти-әниләр дә файдалана ала, алар тәрбияче тәкъдим иткән китапны өйләренә алып кайтып, балалары белән бергә укыйлар һәм укып бетергәч тапшыралар.

Китапханә ачылганнан бирле балаларыбызның китапка мөнәсәбәте яхшы якка үзгәрде. Моның максатка ирешүгә беренче адымнарыбыз гына булуын яхшы белсәк тә, шатландыра.

Хәмдия ТАҖЕТДИНОВА,
Казан шәһәренең 289нчы бакчасы өлкән тәрбиячесе.

«Завод эшчесе кебек эшлим»

Өйдә утырып та завод эшчесе кадәр акча алырга була. Әлбәттә, тик ятып кына түгел. «Зур тырышлык һәм сабырлык белән эшеңне яратып башкарганда, барлык хыяллар да тормышка аша», – дип саный Динара Даутова.

Динара – Чаллы кызы, аңа 20 яшь. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, туризм буенча көллияттә белем ала. Аннары читтән торып, югары уку йортына керә. Уку чыгымнарын каплар өчен, туристик фирмага менеджер булып эшкә урнаша. Параллель рәвештә өйдә кул эше белән шөгыльләнә башлый. Динара фикеренчә, әлеге сәләт нәселдән бирелгән. Кызның ике дәү әнисе дә бәйләмгә, чигүгә битараф булмаган, әнисе юк әйбердән дә күз явын алырлык берәр нәрсә эшләп куя, әтисе дә нәрсәгә тотынса да, башкарып чыга. Динара балалар бакчасына йөргәндә үк, озын үләнгә миләш кидереп, үзенә сәйләннәр эшләгән.

Тик утырганнан эшләнгән бизәнгечләр Динарага тиз арада керем китерә башлый. Үзе дә сизмәстән, төн йокыларын калдырып, көн-төн мәш килә.

– Идеяләр шулкадәр күп, аларны тормышка ашырырга вакыт җитми башлагач, турфирмадагы эшемне калдырдым. Әле хәзер дә, бар булган вакытымны кул эшенә генә багышласам да, ул идеяләрнең кимегәне юк, – ди.

Динара башта полимер балчыктан кулоннар ясый. Матурлыктан тыш, күз тиюдән дә саклый дип, аларга бик күп заказ бирәләр. Тиздән остабикә фоамиран дигән материалны үзләштерә. Аннан чәчәкләр аеруча матур эшләнә икән. Динара ул чәчәкләр белән чәчкә куя торган ободокларны бизи башлый. Үзенчәлекле ободоклар кызларның күңеленә хуш килә, эшләнгән һәр кул эше шундук үз хуҗасын таба. Тиздән чират таҗларга җитә... Монда Динарага бер көндәш тә юк. Һәр таҗ кабатланмас, күз явын алырлык һәм алдан сызылган эскизлар ярдәмендә булачак хуҗаның зәвыгына таянып эшләнә.

– Гаиләбез белән татар эстрадасына битараф түгелбез, һәр башкаручыны яратып тыңлыйбыз. Моннан ике ел элек әти-әнием телевизордан концерт карап утыра. Мине чакырып алдылар да: «Кызым, бу җырчыларга, образларын тулыландырыр өчен, син эшләгән таҗ гына җитми», – диделәр. Бу сүзләргә артык игътибар да итмәдем. Ул вакытта җырчылар минем кул эшләрен киеп сәхнәгә чыгар дип хыялланырга да курка идем. Эшләремнең күбесе интернет аша сатыла, фотосурәтләргә карап сайларга була. Бервакыт миңа җырчылар үзләре мөрәҗәгать итә башламасынмы?! Моңа кадәр популяр кешеләрне бик көйсез, очынган дип уйлый идем. Баксаң, алар бик гади икән. Һәрвакыт минем белән килешәләр, эшләнгән әйберне ошамый дип, үзгәртергә дә теләк белдергәннәре булмады. Ә иң күңеллесе: алар минем әйберләрне киеп чыгыш ясаганда, миндә шулкадәр горурлану хисе! Тәүге концертта хәттә күземә яшь тулды. Сәхнә костюмнарына туры китереп, Фәридә-Алсу таҗлар ясатты. Гүзәлем дә мин эшләгән әйберләрне яратып кия. Илсөя Бәдретдинова алка белән балдакка заказ бирде. Ул теләгәнчә эшләнде, әлеге комплект аңа аеруча килешә. Бүгенге көндә минем кул эшләрендә чыгыш ясаган җырчыларның саны бик күп, – ди оста.

Җырчылардан тыш, Динарага булачак кәләшләр дә заказ бирә. Никах киеменә яулыкларын матур ташлар белән бизәтәләр, ә туй күлмәгенә таҗ ясаталар. Таҗларның хакы аның катлаулылыгы белән бәйле. Уртача 3-5 мең сум тора. Ә инде тагы да биегрәк, ныграк бизәлгәнне сорасалар, кыйммәтрәк тә булуы ихтимал.

Безнең илдә кул эшенә бәя юк, чит илдә мондый әйберләрне чират торып алалар, дигәнне ишеткәнем бар. Миңа калса, бу дөрес түгел. «Сатып алучының таләпләрен үтәгәндә, һәрвакыт уңышка ирешеп була», – ди ул.

– Өйдә генә эшләсәм дә, мин хөкүмәт эшенә йөргән кебек: иртән-иртүк торып эш башлыйм, төшкә ашка бүленәм, аннары тагы эшемне дәвам итәм. Кайчак кичләрен соңга кадәр дә утырыла. Күзләр арый, бил ял сорый башлый... Шуңа кайчак зарядка ясыйм, хәрәкәтләнеп алам. Берүзем генә эшләү авыр. Шуңа да кайчак апам ярдәм итә. Әтием дә шөгылемә битараф түгел: фурнитура сатып алырга кибеткә аның белән йөрим. Аның белән рәхәт: төсләр буенча да киңәшен әйтә, материалның сыйфатын да шундук бәяләп бирә, – ди Динара.

Аның планнары зурдан. Флористика кибетен ачып, кабатланмас букетлар ясамакчы ул. Булачак кәләшләргә таҗ гына түгел, ә чәчәкләр гөлләмәсе дә эшләмәкче. Әлегә эштән тыш вакытын бер дә бушка уздырмый: чәчәкләр өйрәнә, бакчада үскән гөлләрдән букетлар ясап карый.

Зоя СОЛОШИНА.

27 МАЙ – КИТАПХАНӘЛӘР КӨНЕ

Белем алыйм дисәң ничаклы...

Арчаны, хаклы рәвештә, әдәбият һәм мәдәният үзәге дип атарга була. Әдәбиятыбызга Тукайны һәм тагын 30лап талантлы каләм әһелен биргән төбәк ул. Шуңадыр инде Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы да республикада иң зурлардан санала, 57 китапханәне берләштерә. Хәзер традицион кәгазь китаптан – электрон китапка, кәгазь формулярдан Бердәм укучы билетына күчү чоры башланды.

Яңа технологияләр китапханә хезмәте күрсәтүдә әһәмиятле үзгәрешләр дә кертте. Интернет ресурслардан файдалану укучыларның катлаулы сорауларын да канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә. Һәр авыл китапханәсенең үз сайты бар, алар даими рәвештә ике телдә яңартылып барыла.

Китап укучыларны китапханәләргә тагын да күбрәк тарту һәм туплау максатыннан, китапханәсе булмаган авылларда күчмә китапханәләр оештырдык. Йөрмәүчеләргә китапларны өйләренә дә илтеп бирәбез, укысыннар гына.

Кышкарда «Кайтаваз», Яңа Кырлайда «Таяныч», Яңа Кенәрдә «Яшь хокук белгече», Носыда «Гаилә учагы», Сеҗедә «Тургай», Иске Кишеттә «Хуҗабикә», Хәсәншаихтә «Мирас», Шушмабашта «Таяныч» клублары озак еллардан бирле нәтиҗәле эшлиләр. Китапханәләр каршында, татар теле һәм әдәбияты укытучылары ярдәме белән берлектә, «Каләм осталары» түгәрәкләре дә эшли.

Арча шәһәрендә яшәп иҗат иткән, күпсанлы публицистик язмалар, повесть, хикәяләр авторы Радик Фәизов җитәкләгән «Тукай яктышы» әдәби түгәрәге, 2011 елда «Каурый каләм» исеме белән яңа сулыш алып, Үзәк китапханә каршында эшли башлады. Бүгенге көндә берләшмәгә 30дан артык һәвәскәр шагыйрь һәм прозаик йөри. Район хакимияте ярдәме белән, «каурый каләм»леләрнең «Шигъри тәлгәшләр» һәм «Гариф Ахунов премиясе лауреатлары» исемле китаплары басылып чыгу да куанычлы вакыйга булды.

– Һәр елны апрель башында китапханәләр Халыкара балалар китабы көнен билгеләп үтәбез. Әле күптән түгел генә район балалар китапханәсендә шагыйрә Йолдыз Шәрапова белән «Бәллүр каләмле язучы» исемле очрашу кичәсе оештырылды. Тернәкләндерү үзәгенә йөрүче мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен дә әкият геройлары катнашында, театральләштерелгән чаралар, мавыктыргыч кичәләр уза. Әдәби уеннарда катнашу бу балаларның күңелен үстерә.

Район балалар китапханәсе шәһәребезнең балалар бакчалары белән дә тыгыз элемтәдә тора. «Укучының мәдәни көндәлеге» проекты буенча да актив эш алып барыла районыбызда. 2016-2017 уку елында район буенча барлыгы 2214 башлангыч сыйныф укучысына тантаналы төстә шундый көндәлек тапшырылды. Быел укучылар әти-әниләре һәм классташлары белән бергәләп «Иң яхшы иҗади коллектив», «Иң актив мәдәни команда», «Иң мәдәни гаилә» бәйгеләрендә көч сынашалар, – дип хаклы рәвештә горурлана район балалар китапханәсе мөдире Алсу Рәхимбаева.

Соңгы елларда Арчада матур парклар, скверлар төзелә. Көннәр җылыну белән, шул паркларга чыгып, «Әдәби мәйдан»нар, акцияләр, язучыларның юбилей һәм искә алу кичәләрен уздырабыз.

Мөмкинлекләре чикләнгән начар яки бөтенләй күрмәүчеләр, инвалидлар һәм картлар йортында тәрбияләнүчеләр дә китапханәнең актив укучылары. Картлар йортында күчмә китапханә эшли. Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус рәвештә Республика сукырлар китапханәсеннән Брайль шрифты белән басылган һәм аудио китаплар алдырабыз.

Киләчәктә дә яшь буынга гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны өйрәтү, телебезне, моңыбызны саклау, гасырлардан килгән тәрбия үрнәкләрен җиткерүдә ныклы эш алып барырга тырышырбыз.

Лилия ФАЗЫЛОВА,
Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры.

Милләтара дуслык бакчадан башлана

Рус, мари, әзәрбайҗан балалары бергә татар телен өйрәнә. Беренче карашка гаҗәп тоелса да, Совет районының 272нче балалар бакчасында бу гадәти хәл.

– Ике дәүләт телен дә балаларга кечкенәдән өйрәтеп үстерергә кирәк. Балалар бакчасында татар телен өйрәнгән сабыйлар өлкәннәргә дә үрнәк күрсәтәләр. Туган телен, үз милләтең белән горурланып яшәү, гореф-гадәтләрне онытмау бик мөһим. Республикабыз тарихын төрле уеннар аша өйрәтәбез. Татарстанда төрле милләт халыкларының дус, тату яшәвенә зур игътибар бирелә. Без бу татулыкны кечкенәдән үк балаларга сеңдерергә тырышабыз, – ди татар теле тәрбиячесе Эльмира Абдуллина.

272нче балалар бакчасында барлык чаралар да диярлек татар телендә уза. Әле күптән түгел генә анда «Гаилә» бәйрәме гөрләп узды. Әлеге чара беренче генә тапкыр уздырылмый. Оештыручы тәрбиячеләр Фаягөл Мингазова белән Фаянур Сафина әйтүенчә, бәйрәмдә иң талантлы, актив гаиләләр җыела. Дәү әти, дәү әниләр, абый, апалар, әти-әниләр дә тәрбиячеләр оештырган уеннарда, ярышларда теләп катнаша, үз осталыкларын күрсәтә. Гаиләләр үзләре белән таныштыра, милли гореф-гадәтләрен сөйли, өйдән әзерләп килгән милли ризык тәкъдим итә. Уеннар, нәфис сүз музыка җитәкчесе Ольга Егорова әзерләгән җыр-бию белән үрелеп бара. Балалар бакчасында мини театр эшли. Театрның җитәкчесе Гүзәл Идрисова әти-әниләр, балалар катнашында төрле спектакльләр сәхнәләштерә. Мондый формадагы уеннар, аралашу балаларның үзләренә дә бик ошый. Кечкенәдән хөрмәт, ихтирам тәшенчәләрен аңлап үскән балалар киләчәктә дә үзара дустанә мөнәсәбәттә булырлар дип ышана тәрбиячеләр.

Эльвира МОЗАФФАР.

КӨЧЛЕ РУХЛЫЛАР УЕНЫ

МӘДӘНИЯТ

Үзенә яңа проект уйлап табарга кушкач та, Инесса Клюкина инклюзив студия ачу турындагы теләген «Юность» мәдәният сарае директоры Сергей Куприяновка да әйтә. Узган ел үзенең инвалид танышларын җыя да, алар белән спектакль кую эшен башлый. Режиссерларын да, педагогларын да үзе таба. Лилия Хәсәнова белән Неля Суркина инвалид яшьләр белән үзләре иҗат иткән «Сердце города» дигән спектакль куялар. 27 майда алар «Страна сломанных игрушек» дигән спектакльләре белән сөендерәчәк. Анда унсигез кеше катнаша, шуның унөче – физик мөмкинлеге чикләнгән яшьләр.

– Репетицияләрдән тыш без театрларга йөрибез. Киләчәктә яңа спектакльләр куеп, фестивальләрдә катнашасыбыз килә. Җәй көне лагерьда берәр атна яшәп остаханәләр оештырырга ярдәм итүче булса, бик шат булыр идек, – ди Инесса Клюкина.

Миләүшә Әхмәдиева студиягә бизәндерүче кирәклеген интернет аша ишетеп килгән. Аннары вокал дәресләре алып баручы белгеч эзләүләрен белгәч, үзе шушы эшкә алынган, спектакльдә дә уйный. Заманында ул музыка училищесында, педуниверситетның музыка факультетында белем алган.

– Инвалидларның бөтен күңелләрен биреп уйнауларына сокланам. Алар арасында үзеңне икенче төрле тоя башлыйсың. Шулардан көчле рухлы булырга өйрәнәсең. Казанда бу беренче студия. Иң зур кыенлык – мәдәният йортына керү һәм сәхнәгә менү өчен пантуслар булмау. Әлеге студия инвалидларга бер-берсе белән аралашу өчен кирәк. Заманында Мәгариф хезмәткәрләре йортына театр түгәрәгенә йөргәндә, без дә булачак ирем белән танышкан идек. Хәзерге вакытта 21 яшьлек кызым Лилия дә Мотор төзүчеләр клубында музыкаль театр түгәрәгенә йөри. Ире белән аны да театр кавыштырды, – ди ул.

Алинә Шәрәфетдинова церебраль паралич авырулы булуына карамастан, әлеге студиягә үзен сынап карарга килгән. Үзе югары белемле. Психология фәне белән кызыксына. Өйдә ашарга пешерергә ярата.

– Студиядә яңа дуслар таптым. Монда килгәч, үземә ышанычым артты, – ди кыз.

Әйе, инвалид арбасында утырсалар да, вакытларын бушка уздырмый яшьләр. Эзләнәләр, иҗат итәләр. Сәламәт кешеләрне дә үзләренең хезмәт җимешләре белән сокландыралар.

Сигез тәнкыйтьче бәясе

Халыкара Төрки халыкларның XIII «Нәүрүз» Халыкара театр фестивале спектакльләрен сигез танылган театр тәнкыйтьчесе карый һәм бәяли. Алар арасында Мәскәүдән «Вопросы театра» журналының баш мөхәррире Александр Вислов, Уфадан тәнкыйтьче Динә Дәүләтшина, Санкт-Петербургтан «Алтын битлек» премия-фестивале эксперты Татьяна Джурова, Камал театрыннан Нияз Игъламов, Мәскәүдән театр сәнгате институты укытучысы Елена Карась, Екатеринбургтан театр белгече Олег Лоевский һәм башкалар катнашачак. Фестиваль 5 июньдә ачыла. Ул көнне «Агыла да болыт агыла» дигән шигъри спектакль күрсәтеләчәк. Башка спектакльләрне Камал, Тинчурин исемендәге, Яшь тамашачы, «Әкият» Татар дәүләт курчак театрларында күреп булачак.

Камаллылар Тывага җыена

10-11 июньдә Камал театрында Тыва музыкаль драма театрының гастрольләре узачак. Коллектив казанлыларга «Ханума» һәм «Кан-Кыс» спектакльләрен күрсәтәчәк. Әлеге чара алмаш гастрольләр буларак оештырыла. Камаллыларның Тывада гастрольләре кайчан узачагы да билгеле булды. 18 һәм 19 августта камаллылар Кызыл шәһәрендә чыгыш ясый. 18 августта тамашачы Туфан Миңнуллинның «Җанкисәккәем» спектаклен күрә алачак. Бу лирик комедияне тамашачылар бик җылы кабул итәләр, ул үзенең актуальлеген югалтмыйча, инде 20 елдан артык сәхнәдән төшми. (Спектакльнең режиссеры – Фәрит Бикчәнтәев.) 19 августта Галиәсгар Камал пьесасы буенча «Банкрот» (режиссеры – Фәрит Бикчәнтәев) сатирик комедиясе тәкъдим ителә. Спектакль «Алтын Битлек» милли театр премиясенең экспертлар берлеге фикере буенча, Россиянең 2014 елда куелган иң яхшы спектакльләр лонг-битенә керде.

Талантларга юл ачалар

26 майдан 28енә кадәр Казан музыка көллиятендә яшь башкаручыларның Гуммерт исемендәге I Халыкара конкурсы узачак. Анда Россиянең 14 шәһәреннән һәм чит илләрдән 127 музыкант катнаша. Конкурсны, Татарстан Президенты ярдәме белән, Мәдәният министрлыгы, музыка көллияте, консерватория оештыра. Конкурс – көллият директоры Айрат Җаббаров тәкъдиме белән үткәрелә.

Конкурсның Гуммерт исеме белән аталуы очраклы түгел, Заманында композитор, пианиночы Рудольф Гуммерт хор һәм симфоник оркестрның дирижеры була. Ул – Казан музыка көллиятенә нигез салучыларның берсе. Бәйгенең максаты – талантлы музыкантларны югары уку йортларына укырга кертүдә ярдәм итү һәм иҗат коллективларына эшкә урнаштыру. Жюрига Англия, Австрия, Испания илләреннән һәм Мәскәү шәһәрләреннән иң оста скрипкачылар чакырылды. Шулай ук үзебезнең музыка уку йортлары профессорлары, доцентлары да катнашучыларга бәя бирәчәк. Конкурс скрипка, альт, виолончель, контрабас номинацияләрендә уза. Бүләкләү фонды – 650 мең сум. Конкурс вакытында остаханәләр оештыру каралган. Конкурсның йомгаклау концерты Казан Ратушасында узачак.

Сәхифәне Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде.

ҖОМГА ВӘГАЗЕ

РАМАЗАН АЕНЫҢ

Ислам динендә 12 айның иң зурысы булып Рамазан ае санала. Күп кеше Рамазан аеның кадерен белми, бу айны, ураза тотмыйча, гөнаһлар кылып үткәрә. Әгәр дә алар Рамазан аеның нинди кадерле вә изге ай икәнен белсәләр, дөнья эшләрен калдырып, Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылырлар һәм көннәрне вә төннәрне хәерле гамәлләрдә үткәрерләр иде. Ислам галимнәре Рамазан аеның башка айларга караганда өстенлеген түбәндәгечә аңлата:

Илдар Мөхәммәтҗанов фотоархивыннан

1.Аллаһ Тәгалә бу айда ураза тотуны фарыз кылды;

Аллаһ Тәгалә ураза тотуны Мөхәммәд (с.г.с.) өммәтенә генә фарыз кылмады, ә бөтен алда килеп киткән пәйгамбәрләрнең дә өммәтләренә фарыз итте.

Мөхәммәд (с.г.с.) ураза тотуның фазыйләте турында шулай дип әйтә:

«Адәм баласының һәр гамәле өчен әҗер-савап арттырып бирелә. Бер яхшы гамәлгә әҗер-савап уннан алып 700гә хәтле арттырыла. Аллаһ Тәгалә шулай ди: «Бу – уразадан башка гамәлләр өчен генә. Дөреслектә, ураза ул Минем өчен һәм Мин аңа Үзем әҗер-савабын бирәм. Чөнки ул нәфес теләген һәм ризыгын Минем өчен калдыра. Ураза тотучының ике шатлыгы бар: бер шатлыгы авыз ачканда, ә икенчесе Раббысы белән очрашканда» (Мөслим, 1151).

Рамазан аенда ураза тоту гөнаһлардан котылырга ярдәм итә. Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди:

«Кем дә кем Рамазан аенда Аллаһның әҗер-савап бирүенә ышанып һәм Аның ризалыгын өмет итеп ураза тотса, аның элеккеге гөнаһлары гафу ителә» (Бохари, 38).

Имам ән-Нәвави аңлатуынча, бу хәдистә сүз кечкенә гөнаһлар турында бара. Чөнки Мөхәммәд (с.г.с.) башка бер хәдистә:

«Биш вакыт намаз уку, бер җомга намазын укыганнан соң икенче җомга намазын уку, Рамазан аенда ураза тотканнан соң икенче Рамазан аенда ураза тоту алар арасында булган гөнаһларның гафу ителүенә сәбәпче булып торалар, әгәр дә кеше олы гөнаһлардан сакланса», – ди (Мөслим, 574).

Ә олы гөнаһларга килсәк, алардан котылу өчен кеше тәүбә итәргә тиеш.

Уразага керер алдыннан төнлә торып (сәхәр) ашау сөннәт гамәл булып санала. Бу гамәл безне яһүдләр һәм насаралар уразасыннан аерып тора. Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди: ***«Безнең ураза белән китап әһелләренең уразасы арасындагы аерма – ул төнлә торып ашауда»*** (Мөслим, 2604).

Әгәр дә кеше сәхәр ашаса, Аллаһ Тәгалә аның ризыгына, байлыгына, эшенә, гаиләсенә һәм үзенә бәрәкәт бирә. Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди:

«Уразага керер алдыннан төнлә торып ашагыз, чөнки сәхәр вакытында бәрәкәт бар» (Бохари,1923).

Шулай ук Рамазан аенда ураза тотучы кешене ашату да бик изге вә әҗер-саваплы гамәл булып санала. Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди:

«Кем дә кем ураза тотучыны ашатса, аңа ураза тотучының әҗер-савабыннан киметелмичә әҗер-савап булачак» (Тирмизи, 807).

2.Рамазан аенда күк һәм җәннәт ишекләре ачыла, ә җәһәннәм ишекләре ябыла;

Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди:

«Әгәр дә Рамазан ае килсә, җәннәт ишекләре ачыла» (Бохари, 1898).

Икенче бер хәдистә Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди:

«Әгәр дә Рамазан ае керсә, күк ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, ә шайтаннар чылбырга бәйләнеп куела» (Бохари, 1899).

3. Рамазан аенда «Ләйләтүл-кадер» – кадер кичәсе бар;

Бу кичә мең айдан да хәерлерәк. Аллаһ Тәгалә ул төндә ел әйләнәсендә булачак вакыйгаларны билгели. Бу вакыйгаларны тормышка ашыру өчен, Ул аны билгеле бер фәрештәләргә йөкли. Кем дә кем аның әҗер-савабыннан мәхрүм калса, ул чыннан да күп нәрсәдән мәхрүм калган кеше була. Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди: ***«Сезгә бәрәкәтле Рамазан ае килде. Аллаһ Тәгалә сезгә бу айда ураза тотарга кушты. Бу айда күк ишекләре ачыла, ә җәһәннәм ишекләре ябыла, иң азган шайтаннар богаулар белән бәйләп куела. Аллаһ Тәгаләнең бу айда бер кичәсе бар. Ул мең айдан да хәерлерәк. Кем дә кем анда биреләчәк хәерле нәрсәдән мәхрүм калса, ул чыннан да мәхрүм калган кеше була»*** (Нәсәи, 2118).

Әгәр дә кеше бу кичәдә бик күп төнге намазлар укыса, аның кечкенә гөнаһлары гафу ителә. Кадер кичәсендә җир йөзенә бик күп фәрештәләр иңә. Бу фәрештәләр гыйбадәт кылучы мөселманнар өчен дога кылалар, Аллаһ Тәгаләдән гөнаһларын гафу итүне сорыйлар.

4. Рамазан аенда кылынган гомрә хаҗ кылуга тиңләшә;

Ягъни Аллаһ Тәгалә ул кешегә хаҗ кылган шикелле әҗер-савап яза. Мөхәммәд (с.г.с.) Мәдинә шәһәрендәге бер хатынга шулай дип әйтте:

«Әгәр дә Рамазан ае җитсә, Гумра кыл. Дөреслектә, Рамазанда кылынган гомрә хаҗга тиң» (Бохари).

Ләкин бу Зүл-Хиҗҗә аендагы хаҗны өстән төшерми, ул шулай ук кылганчыга хәтле фарыз булып кала.

5.Рамазан ае ул – тәравих намазын уку ае;

Мөхәммәд (с.г.с.) шулай ди:

«Кем дә кем Рамазан аенда Аллаһның әҗер-савап бирүенә ышанып һәм Аның ризалыгын өмет итеп тәравих намазын укыса, аның элеккеге гөнаһлары гафу ителә» (Бохари, 37).

Шулай ук бу хәдистә дә кечкенә гөнаһлар турында сүз бара.

6. Рамазан аенда, башка айларга караганда, сәдакага әҗер-савап күбрәк бирелә;

Әнәс ибн Мәлик әйтә: «Бервакытны Мөхәммәд (с.г.с.)нән: «Рамазаннан соң кайсы айда ураза тоту хәерлерәк?» – дип сорадылар. Ул: ***«Рамазанны зурлау өчен Шәгъбән аенда тотылган ураза», – дип җавап бирде. Шуннан соң: «Кайсы сәдака саваплырак», – дип сорадылар. Ул: «Рамазан аенда бирелгән сәдака», – дип әйтте»*** (Тирмизи, 665).

Шуңа күрә мөселман кешесе бу айда мохтаҗ кешеләргә күбрәк сәдака бирергә һәм юмартлык күрсәтергә тиеш.

7. Рамазан ае ул – җәһәннәмнән котылу ае;

Мөхәммәд (с.г.с.) бу турыда шулай дип әйтә: «Рамазан аеның беренче кичәсе җитсә, шайтаннар һәм җеннәрнең иң начарлары богаулап куела. Бу айда җәһәннәм ишекләре ябыла һәм аның бер ишеге дә ачылмый, ә җәннәт ишекләре ачыла һәм аның бер ишеге дә ябылмый. Ул айда бер фәрештә: ***«Әй изгелек кылырга теләүче! Күбрәк изгелек кыл! Әй гөнаһлар кылырга теләүче! Гөнаһлар кылудан тукта!» – дип аваз сала. Аллаһ Тәгалә бу айның һәр төнендә билгеле бер кешеләрне җәһәннәм утыннан азат итә»*** (Тирмизи, 684).

РАМАЗАН – УРАЗА АЕ

Аллаһ Тәгалә Коръәндә Рамазан аеның фазыйләте турында шулай ди:

«Рамазан аенда кешеләргә туры юлны күрсәтүче, дөрес юлның һәм аеручының ачык дәлилләре буларак Коръән иңдерелде. Сездән кем дә кем бу айга җитсә, ураза тотсын. Әгәр кем дә кем авыру яки сәфәрдә булса, шул ук санда башка көннәрдә ураза тотсын. Аллаһ сезгә җиңеллек тели, ә авырлык теләми. Ул билгеле сандагы көннәрне ахырына җиткерүне һәм сезгә туры юлны күрсәткәне өчен Аллаһны зурлавыгызны тели. Бәлки сез шөкер итәрсез» (Бәкара, 185).

Аллаһ Тәгалә бөтен кешелеккә дөрес яшәү рәвешен күрсәтүче, тормышта мөһим булган нәрсәләрне аңлатучы Коръәнне Рамазан аенда иңдерде. Рамазан гарәп телендә «рамад» сүзеннән барлыкка килгән. Бу сүз «эссе», «кызу» дигән мәгънәне белдерә. Гарәпләр элекке вакытта айларга исемнәрне табигать күренешләренә карап куша торган булган. Бу ай кояш бик нык кыздырган вакытка туры килгәнгә, аны «рамадан» (кыздыручы, кайнар) дип атаганнар.

Рамазан ул – рухи тәрбия, гыйлем алу, Коръәнне уку һәм аның

ФАЗЫЙЛӘТЕ

мәгънәләрен өйрәнү ае. Шуңа күрә кешеләр бу айда дини гыйлем алуга, Коръән китабын күбрәк укуга игътибар итәргә тиеш.

Кеше уразаны дөрес ният белән тотарга тиеш. Кешеләрнең кайберләре уразаны ябыгу өчен яки авырулардан сәламәтләнү өчен тота. Чынлыкта мондый ният белән тотылган уразаны Аллаһ кабул итми. Чөнки бу очракта ураза Аллаһ ризалыгы өчен түгел, ә ниндидер дөньяви файда өчен тотыла. Ихласлы кеше уразаны Аллаһның әмерен үтим һәм Аның ризалыгына ирешәм дигән ният белән тотарга тиеш.

Шулай ук кешеләрнең күбесе ураза тотуның асыл мәгънәсен аңламый. Алар фикеренчә, ураза ул – ашау-эчүдән генә тыелып тору. Ләкин ураза – ашау-эчүдән генә түгел, ә бөтен гөнаһлы гамәлләрдән тыелу. Рамазан аенда кешенең бөтен әгъзалары да ураза тотарга тиешле. Теле дә, кулы да, күзе дә, аяклары да. Шуңа күрә уразада ашау-эчүдән тыелып, әгайбәттән, ялган сөйләүдән, сүгенүдән, кеше рәнҗетүдән һәм әрләшүдән тыелмаган кеше көне буе ач торучы гына булып санала. Аллаһ Тәгалә аңа бернинди дә әҗер-савап бирми. Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.с.) әйтә:

«Кем дә кем ураза вакытында ялганны һәм аның белән гамәл кылуны калдырмаса, Аллаһка аның ашау-эчүдән тыелып торуы кирәк түгел» (Бохари).

Чынлыкта, Аллаһ Тәгалә кешеләргә ураза тотуны авырлык тудыру өчен йөкләмәде. Аллаһ Тәгалә ураза аркылы кешеләрнең җаннарын һәм тәннәрен тәрбияли, аларга башка айларда бирелмәгән әҗер-савапларны бирә. Аллаһ Тәгалә – Рәхимле һәм хикмәт Иясе, шуңа күрә дә Ул ураза тотудан авыру һәм сәфәрдә булган кешеләрне азат итте. Галимнәр аңлатуынча, әгәр дә кеше таң атканчы 90 чакрым ераклыктагы юлга чыкса, ураза тотмый ала. Ләкин Әбү Хәнифә мәзһәбендә әгәр дә юл авыр булмаса, ураза тоту хәерлерәк.

Кеше авыру яки сәфәрдә булу сәбәпле уразасын калдырса, сәламәтләнгәч һәм сәфәрдән кайткач, уразаны тотып бетерергә тиеш була.

УРАЗАНЫҢ КАБУЛ БУЛУ БИЛГЕЛӘРЕ

Аллаһ Тәгалә фарыз кылган һәр гыйбадәт билгеле бер максатка ия. Ислам динендә адәм балаларына бер әмер дә һәм бер тыю да максатсыз һәм хикмәтсез билгеләнмәде. Шуннан чыгып, ураза тотуның да билгеле бер максаты бар, ул – тәкъвалык сыйфатына ирешү. Аллаһ Тәгалә әйтә: **«Әй иман китергән бәндәләр! Сезгә хәтле булганнарга ураза тоту фарыз булган кебек, сезгә дә ураза тоту фарыз булды. Бәлки сез тәкъва булырсыз»** (Бәкара, 183).

Тәкъвалык ул Аллаһның газабы белән үзеңнең араңа саклаучы бер киртә куюны аңлата. Моңа, иң беренче чиратта, фарыз гамәлләрне үтәү һәм гөнаһлардан тыелу керә. Әгәр дә кеше Рамазаннан йөрәгеен һәм әгъзаларын тутыручы тәкъвалык белән чыкмаса, бу аның тоткан уразасыннан файда алмавын күрсәтә.

Элеккеге мөселманнар Аллаһка, Рамазан аена ирештерүне сорап, алты ай буе дога кылалар иде. Әгәр дә Рамазан ае узса, алар тоткан уразаны кабул итүне сорап, шулай ук алты ай буе дога кыла торган булдылар. Моның мәгънәсе, алар ел буе Рамазан аен онытмады (Ибн Раҗәб әл-Хәнбәли, «Ләтаифуль-мәгариф»).

Рамазанда кемдер уңышка иреште, ә кемдер югалту кичерде. Аллаһ каршында уңышка ирешкән кеше – уразасы кабул булган, гөнаһлары кичерелгән кеше. Югалту кичерүче кешегә килсәк, ул – уразасы кабул булмаган, әхлагы яхшырмаган һәм гөнаһлары кичерелмәгән бәндә.

Бөтен кеше дә Рамазан беткәннән соң тоткан уразасы кабул булуын, гөнаһлары гафу ителүен тели, әмма Аллаһ Тәгалә кайбер кешеләрнең уразасын кабул итә, ә кайберләренеке кабул итми.

Ислам галимнәре Аллаһ каршында тоткан уразаның кабул булуын күрсәтүче кайбер хикмәтләр турында хәбәр итте. Әгәр дә кеше шушы галәмәтләрне белсә, үзенә уңай яки тискәре яктан бәя бирер һәм кимчелекле якларын төзәтер. Рамазан уразасының кабул булуы һәм аннан файда алуның билгеләре түбәндәгеләр:

1. Рамазан аенда гөнаһ кылудан туктап, шул гөнаһка әйләнеп кайтмау;

Рамазан аенда гөнаһтан тыелып, бу ай беткәннән соң яңадан шул ук гөнаһка әйләнеп кайту – ураза тотудан файда алмауның һәм әҗер-савапка ирешмәүнең бер билгесе. Коръәндә Аллаһ Тәгалә андый кешене эрләгән җебеннән кием тегеп, аны сүткән хатын-кыз белән чагыштыра. Аллаһ Тәгалә әйтә:

«Оста итеп эрләгәннән соң җебен сүтеп бетерегән хатын кебек булмагыз» (Нәхел, 92).

Тәфсир галиме Ибн Кәсир әйтә: «Борын заманда Мәккә шәһәрендә җеп эрләүче бер ахмак хатын яшәгән. Оста итеп җеп эрләгәннән соң, ул аны сүтә торган булган».

Аллаһ Тәгалә бу мисалны вәгъдә биреп, ант итеп, сүзендә тормаучы кешеләргә карата китерә. Бу шулай ук гөнаһтан тәүбә итеп берникадәр вакыттан соң яңадан шул ук гөнаһларны эшләүчегә дә кагыла. Андыйлар турында Мөхәммәд (с.г.с.) бер хәдисендә шулай ди:

«Кайбер ураза тотучыга уразасыннан бары тик ач торуы гына кала, ә кайбер төнлә намаз укучыга төнге намазыннан бары тик йокламыйча төн уздыруы гына кала» (Сахихул-Җәмигъ, 3488).

Галимнәр әйтүенчә, хәдистәге «ач торудан башка нәрсәгә ирешмәүче» хәрам ризык ашаучы һәм гайбәт сөйләүчене аңлата.

Әл-Бәйдави әйтә: «Ураза тотарга әмер ителүнең төп максаты ашамый-эчми торудан гыйбарәт түгел. Аны тотуда төп максат – шәһвәт теләген сындыру, гөнаһка этәрүче җанны Аллаһка буйсындыру. Әгәр бу тормышка ашмаса, Аллаһ Тәгалә кешенең уразасын кабул итмәячәк».

Мөхәммәд (с.г.с.) әйтте: ***«Ураза ул ашау-эчүдән генә тыелып тору түгел. Дөреслектә, ураза ул – буш сүздән һәм гөнаһлы гамәлләрдән тыелу...»*** (Сахихул-Җәмигъ, 1082).

Яхйә ибн Мөгаз әйтә: «Кем дә кем уразада теле белән Аллаһтан гафу итүне сораса, ләкин Рамазан ае беткәч йөрәге белән шул гөнаһны теләсә һәм уразадан соң аны кыла башласа, ул кешенең йөрәге гөнаһ белән бәйләнгән, уразасы кире кагылган һәм кабул булу ишеге аның өчен ябылган була».

Шушы сүзләрдән чыгып, Рамазаннан соң кире гөнаһ кылуга әйләнеп кайту – тәкъвалык дәрәҗәсенә ирешмәүне күрсәтүче бер билге. Аллаһ Тәгалә андый кешеләрнең тоткан уразаларын кабул итмәскә мөмкин. Аллаһ Тәгалә шулай ди:

«Аллаһ бары тик тәкъва кешеләрдән генә кабул итә» (Мәидә, 27).

Алда әйтелгәнчә, тәкъвалык ул җәһәннәм газабы белән үзеңнең араңда пәрдә куюны аңлата. Әгәр дә кеше ураза тотып, яхшы якка үзгәрсә, гөнаһлардан тыела башласа, изге гамәлләргә омтылса, бу аның Рамазан аеннан файда алуын һәм уразасының кабул булуын күрсәтә.

Күп кеше Рамазан аенда тәүбә итә, ләкин эченнән: «Дөреслектә, мин кире гөнаһка кайтуымны беләм», – ди. Андый кеше Аллаһтан ярдәм сорап, «Иншә'Аллаһ – Аллаһ теләсә мин гөнаһ кылмаячакмын», – дип үз-үзенә сүз бирергә тиеш. Әгәр дә ул ихласлы булса, Аллаһ Тәгалә аңа ярдәм итәчәк.

2. Кылган гамәлләренең кабул булмавыннан курку;

Рамазан аенда ураза тотудан файда алган кеше, хәерле гамәлләрне бик күп кылуына карамастан, Аллаһ каршында үз гамәлләренең кабул булмавыннан курка. Шуңа күрә ул Аллаһның гафу итүенә вә рәхмәтенә өметләнә.

3. Рамазаннан соң дәвамлы рәвештә хәерле гамәлләр кылу;

Аллаһ Тәгалә тоткан уразаларыбызны кабул итсен, гөнаһларыбызны кичерсен һәм киләсе Рамазан аена хәтле изге гамәлләр кылырга ярдәм итсен. Әмин!

Алмаз хәзрәт САФИН,
«Өметләләр» мәчете
имам хатибы.

ПОЧТАДАН

Нәкъ шулай. Нинди генә халәттә булсаң да, көзге салкын яңгырдамы, йә кышкы ачы бураннарда кар ярып барасыңмы – бирегә килеп керүеңә, сине ачык йөзле Рәсилә, Минзифа, Тәскирә, Руфияләр үз туганнарын каршылагандай кочаклап каршы алалар. Нинди генә чара узса, алар һәркайсы энтәлекле, һәркем аңларлык гади дә, мавыктыргыч та итеп оештырыла. Бу бәйрәм чараларын шушы мәчеттә 16 ел уку-укыту эшләре җитәкчесе, галимә-абыстаебыз Фәния Җәләлиева оештыра.

Рухи ләззәт алырга... «Гадел»гә

Быелгы уку елын тәмамлау уңаеннан барлык мәчетләрдә чыгарылыш чаралары уза. Әлбәттә инде, «Гадел» мәчете бу гаҗәеп бәйрәм мәҗлесләренә кушылмый калмый. Әле җитмәсә Фәния Җәләлиеваның яңа гына чыккан «Күңелләр дәвасы» китабын (мөхәррире Вәсилә Рәхимова) укып бик тәэсирләнгән көннәрем дә иде. 20 елга якын аралашып яшәвебезгә карамастан, хөрмәтле абыстаебызны аз белгәнмен икән! Үтә дә ихласлыгын белсәм дә, шулхәтле үк тыйнак дип уема да килмәгән. Чын каһарман икән ул, яман чирне җиңә алган. Монда үзе табибә булуы, медицинаны «а»дан «я»га хәтле белүе генә, шәхсән ихтыяри көче-куәте түгел, ә Аллаһы Тәгаләгә җаны-тәне, бөтен барлыгы белән ихлас ышануы да булышкан аңа! Ире – хәрби табиб Рәшит, сеңлесе – югары категорияле табиб Әлфия, балалары, туганнары да гел янәшәсендә булган.

Фәния «Гадел» мәчете ачылуның беренче көннәреннән үк эшкә тотына. Аның башлангыч дини укыту программасын Диния нәзарәте хуплап кабул итә. Ә программа төзү-язуны аңа Вәлиулла хәзрәт Якупов үзе тәкъдим итә. Ул «Гадел» мәчетендә генә түгел, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсендә кечке бүлектә укучыларына әдәп-әхлак дәресе, хатын-кызларга Коръәнне дөрес итеп уку дәресләрен укыта. Кукмара районының Өркеш авылында туган нигезләрендә үз көчләре, хисаплары белән төзелгән мәдрәсәдә уку-укытуларның барышын оештырып, тикшереп торса, кышкы-җәйге лагерьларда яшь мөгаллимәләргә, студентларга, балаларга тәрбияви-спорт уеннары, күренекле шәхесләребез белән очрашулар, Сабан туйлары кебек онытылмас бәйрәмнәр уздырыла. Үткән җәйдә Өркеш халкы бу гаиләдән тагын бер зур бүләк алды – мәһабәт мәчет ачылып, хәзер аннан нурлы-моңлы азан яңгырап, үзенә чакырып тора.

Калеб кыйбласын, күңелләр дәвасын күрсәтүче Фәния абыстайга шәкертләре дә бик рәхмәтле.

– Олы исәпләр, дәрт белән өйрәнеп йөргәндә, оныкларым туып, аларны карарга туры килде, дәресләрем калды. Әллә оныкларымны арбада бик артык тартып йөрештем, әллә салкын тиде – аяклар йөрми башлап, урынга яттым. Шунда Фәния абыстайкаемның сүзләре исемә төште: «Укы! Укы!» Дәресләкләремне, Коръәнемне алып укыдым, аякка басуга, «Гадел»емә килдем, Фәния абыстайны Аллаһы Тәгалә безгә якты юл күрсәтү өчен җибәргән! – ди Миләүшә ханым.

...Чыгарылыш бәйрәменә кунак кызлар, малайлар да килгән иде, алар да үз осталыкларын күрсәтеп сөендерде җыендагыларны. Вәсилә Рәхимованың оныгы – 8 яшьлек Фәридә Әхмәтова – «Ихлас» сүрәсен сөйләп күрсәтте. «Әнисе Диләрә дә намазда, шөкер, – ди Вәсилә абыстай, – олы оныгым Фәридә Каравайдагы «Нурислам» мәчетендә укыды.

Нагорный бистәсендәге «Иман нуры» мәчете мөгаллимәсе Гөлзада Шәяхмәтова да укучысы Айзилә Ислам кызын алып килгән. 9 яшьлек бу гүзәлкәебез бик матур итеп «Әлхәм» сүрәсен укыды. «13 ел укытам, – ди Гөлзада, – ара ерак булса да, «Гадел»гә киләсе килеп тора. Фәния абыстаебызның фидакярлегеннән өйрәнәбез. Аллаһы Тәгаләнең әҗер-саваплары ясусын, беркүк, исән-сау гына була күрсен дибез! Биредә күңелләргә рухи көч алабыз!»

Әйе. Кайчан килсәң дә, биредә ләззәт алып, дөньяларың яктырып кайтасың шул... Афәрин!

Мөслимә ШӘФЫЙК.

«Тамашачыны тәрбияләргә түгел, бозмаска кирәк»

Казан федераль университетының «Tataristica» үзәгендә «Татар театры: югалту һәм табышлар» темасына дискуссия узган иде. Анда куелган төп сорау: глобальләшү шартларында милли театрлар үз йөзен саклап кала алырмы? Шунда яңгыраган кайбер фикерләрне сезгә тәкъдим итәбез.

Алисә САБИРОВА

Фәрит Бикчәнтәев, *Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры:*

– Глобальләшү татар театрына гына кагылмый. Без «Нәүрүз» фестивале оештырабыз. Анда бөтен Россиядән, элеккеге СССР республикаларыннан театрлар килә. Алтай, Хакассия театрларының үз телләреннән әкренләп читенә барулары күзәтелә. Россия буенча күп кенә милли театрлар үз телләрендә спектакль уйнарга курка. Кайбер театрларга бары тик үз телләрендә генә уйнау шарты куябыз. Шуннан соң алар аны яңадан тәрҗемә итеп, өйрәнеп килә. Татар театрларында да андый очраклар күренгәли. Әлбәттә, без театрларга «урысча уйнамагыз» дип күрсәтмә бирә алмыйбыз. Бүген бит театр матди ягын да карарга тиеш.

Дамир Самерханов, *Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театрының баш режиссеры:*

– Минзәләдә 17 мең халык яши, шуларның 6 меңе генә татар. Русча спектакльләр куйсак та, без бит Тукайны уйныйбыз. Бу бит урыс балалары да татар классикасы белән таныша дигән сүз. Мин моны татар мәдәниятенә хилафлык китерү дип санамыйм. Театр яшәргә тиеш. Заманасы шундый булгач, бу инде яшәешнең бер чарасы гына.

Әлфәт Закирҗанов, *Казан федераль университеты профессоры:*

– Татар театры – милли яшәешнең бер тармагы. Шуңа да милли йөзебезне театр аша күрсәтергә тиешбез. Алда әйтелгәннәр белән берничек тә килешә алмыйм. Мәскәү, Санкт-Петербург, Европа тамашачысына без үз телебезне, этнографиябезне күрсәткән әсәрләр белән генә кызыклы. Рус теленә күчәбез икән, бертөрлегә әйләнәбез түгелме? 80нче елларда Мордовиядә, мордва әдәбияты кайсы телдә булырга тиеш, дигән мәсьәлә куелды. Ул вакытта «алар рус телендә булсын, ләкин аның эчтәлеге милли мәсьәләгә юнәлтелгән булырга тиеш» дигән карарга киленде. Бүген Мордовиядә милли телдә иҗат итүче бер генә язучы да юк. Әлеге куркыныч безгә дә яный. Татар театры бары татар телендә һәм бөтен милли гореф-гадәтләрне яклап һәм саклап кына яши ала. Ул шуның белән үз йөзен саклый.

Илгиз Зәйниев, *драматург һәм режиссер:*

– Минем өчен бу проблемалар гомумән юк. Татар театры икән, ул татарча уйнарга тиеш. Әгәр дә татар театры русча уйный икән, моның сәбәбен табып, хәл итәргә кирәк. Нәрсә генә әйтсәк тә, ул акча белән бәйле. Димәк, дәүләт театрларны андый хәлгә төшерергә тиеш түгел.

Илдар Хәйруллин, *Камал театры актеры, Казан театр училищесы педагогы:*

– Рус телендә спектакль уйнау театрның гаебе түгел. Билет алучы юк. Татар телендә аралашучы кеше юк. Оешмаларда татар телен саклау фонды булып та, алар: «Спектакль татарча булса, билет алмыйбыз», – дип тора. Монда хөкүмәт тә гаепле түгел. Без үзебез гаепле. Үз балаларыбызны татар рухында тәрбияли алмыйбыз икән, димәк, без үз милләтебезгә хөрмәт белән карамыйбыз. Театр әсәре драматургиядән туа. Без XXI гасырда яшибез, ләкин һаман да Тукай бабай уйлап чыгарган «Кәҗә белән Сарык» әсәреннән ерак китә алмыйбыз. Илгиз бердәнбер «Кечтүкле уен» әсәрен чыгарды. Аңа халык күп килде. Ә башка театрлар әйләндерәләр дә шул «Кәҗә белән Сарык»ны куялар. Интернет заманасы – бөтенләй башка технологияләр чоры. Шуларны уйлап язарга кирәк. Бүген драматургиябез авыру хәлдә.

Фәрит Бикчәнтәев:

– Тамашачыны тәрбияләргә түгел, аны бозмаска кирәк. Тамашачы беркайчан да акылсыз булмады, аннан дивана ясарга кирәк түгел. Тамашачы театрга караганда бөегрәк. Аны хөрмәт итәргә кирәк. Татарстанда да, безнең халык дурак, аңа бата, дип йөрүче режиссерлар бар. Без үзебез, үз тамашачыбызны шулай бозабыз. Аннан соң, алар мәгънәле куйган әйберләрне кабул итми, дип зарланабыз. Итәләр, җәмәгать! Юлларын табарга кирәк. Безнең дә андый хәлгә төшкәнебез бар. 90нчы елларда, бөтен театрлар «янган» вакытта, тамашачы йөрсен дип, ай саен яңа премьера куеп бозып бетердек халыкны. Бүген бу проблеманы чиштек: лабораторияләр эшләдек, кече заллар җыя башладык. Хәзер халык зур залда барган җитди әсәрләрне дә кабул итә. «Курчак туе» биш сезон халыкны аншлаг белән тотты. «Арбалы хатыннар» дүрт ел барды. Хәзер «Дон Жуан» бара. «Мулла»га һаман аншлаг. Зөлфәтнең «Телсез күке»се биш сезон торды. Нинди җитди, катлаулы әсәр. Анда мондый сүзләр бар. Персонаж: «Эх яратмыйлар безнең татарны», – дигәч, фин татары: «Ни эшләп сезне яратырга тиешләр, яратсын үзен татар», – ди. Милли сәнгатьтә урталыкны табуы авыр. Зыялылыкны да, тамашачыны да югалтмаска кирәк.

«Казан ипподромы» ярминкәгә чакыра

Халыкара ат-спорт комплексында халык куллануы товарлары ярминкәсе ачыла.

Балага – яңа куртка, әти-әниләргә җәйге аяк киеме кирәкме, бер уңайдан интерьерда нәрсәдер яңартырга телисез, ә дачада җиләк-җимеш һәм яшелчә культуралары утыртырга вакыт җиттеме. Ниндидер тәмле әйбер ашыйсыгыз яки нәрсәгә булса да өйрәнәсегез киләме. Мондый күпкырлы теләкләр белән күпләр очрашкандыр, әлбәттә, тик менә аларны үтәве генә җиңел түгел, бер кибеттән икенчесенә чабарга туры килә. Ярминкә исә – бөтенләй икенче, биредә барлык кирәкле әйберләр бер урында тупланган. Бәяләре дә кесәгә артык сукмый, сыйфаты югары, сатып алучыга тагын ни кирәк. Әгәр моңа тагын гадәти булмаган урынны да өстәсәк. **Халыкара ат-спорт комплексындагы күргәзмә, күппрофильле объект буларак, ипподромны үстерү программасы кысаларында уза. Чара ат-спорт комплексының милекчесе – «Татспиртпром» АҖ башлангычы белән, күргәзмәнең мәгълүмати партнеры – БИМ-радио теләктәшлегендә үткәрелә.**

Компания тырышлыгы белән хәзер биредә ат чабышларыннан тыш, башка чаралар да оештырыла. 25-29 май көннәрендә төп трибуна комплексында җаның теләгән бөтен әйберне (өс һәм аяк киемнәреннән башлап азык-төлек продуктларына кадәр) табып булачак. Соңгысына аерым басым ясаганнар – сезгә күптөрле балык һәм ит деликатеслары, кондитер эшләнмәләре, балык һәм умартачылык продуктлары тәкъдим итәчәкләр. Сатып алганны, продукцияне татып карау мөмкинлеге дә бар.

Күргәзмә ипподром территориясендә беренче мәртәбә узуы белән генә түгел, гомумшәһәр һәм төбәк күргәзмә чаралары, ярминкә һәм бәйрәмнәр циклын ачып җибәрүе белән дә үзенчәлекле. Хәзер алар ипподром территориясендә даими рәвештә узачак. Әлеге ярминкәдә азык-төлек белән генә чикләнеп калмаячаклар. Шулай ук өс һәм аяк киемнәренең бай ассортименты, өлкәннәр һәм балалар өчен аксессуарлар, җәйге ял һәм дача сезонында кирәге чыгачак товарлар тәкъдим ителер дип көтелә.

Татарстан халык һөнәрчелеге һәм кәсепчелеге үзәге осталарына аерым экспозиция багышланган. Монда ниләр генә юк: күн, мех, металл, керамик эшләнмәләр, интерьер әйберләре, дизайнер киемнәре, кулдан ясалган бизәнгечләр… Ярминкә «Казан ипподромы»на керү юлында ук үз эшен башлый. Ачык мәйданчыкта Татарстанның фермер хуҗалыклары үзләре җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясе белән сәүдә итә. Бакчачыларга исә югары сыйфатлы һәм элиталы үсентеләр, җиләк-җимеш, чәчәк, декоратив, яшелчә культуралары, орлыклар, экзотик һәм бүлмә гөлләре, ландшафт дизайны товарлары тәкъдим ителә. Бер сүз белән әйткәндә, барысы да бик кирәкле һәм җитештерүче бәяләреннән.

Күргәзмә-ярминкә ул сәүдә генә түгел. 25-29 май көннәрендә «Казан ипподромы»нда кунаклар өчен күп кенә кызыклы һәм файдалы мастер-класслар узачак. Мондый ярминкәнең гамәли кыйммәте арткан-арта баруы көн кебек ачык. Кунаклар яңа идеяләр һәм гамәли күнекмәләр ала, тәҗрибә туплый.

Оештыручылар ярминкәдә һәркемнең үзен кызыксындырган әйбер табачагына ышандыра. Балалары белән килүче ата-аналар өчен ипподром территориясендә биш көн дәвамында аттракционнар паркы эшли. Өлкәннәр әйбер сатып алу белән мәшгуль булган арада, балалар батутта сикерә, күңелле паровозга утырып йөри, татлы мамык, попкорн һәм туңдырма белән сыйлана ала. «Казан ипподромы» ул ат чабышлары үткәрү урыны гына түгел, ә күпфункцияле мәйданчык та. 25-29 май көннәрендә биредә җитештерүче бәяләреннән һәм турыдан-туры үзләреннән өс һәм аяк киемнәре, аксессуарлар, халык һөнәрчелеге товарлары, фермер продуктлары, бакча өчен кирәк-яраклар (үсентеләрдән алып декор элементларына кадәр) сатып алырга мөмкин. Күргәзмә-ярминкә кунаклары өчен бөтен шартлар тудырылган – барысы да уңайлы урнашкан, балаларга кызыклы шөгыльләр җитәрлек, парковка якында гына – «тимер ат»ны кайда калдырыйм икән дип баш ватасы юк.

Реклама

Сатып алучыга кайда ярдәм итәләр?

«Атна вакыйгалары» газетасы «Кулланучы хәбәрләре» дигән рубрика ачып җибәрә. Сатып алучыга кемнәр һәм ничек ярдәм итә ала. Өстәмә хезмәтләр көчләп такмыйлармы. Интернетта товар сатып алганда тиешле мәгълүмат бирмиләрме. 2017 ел дәвамында әнә шулар турында җентекле мәгълүматлар дөнья күрәчәк.

НӘРСӘГӘ ЗАРЛАНАЛАР?

Быелның дүрт ае эчендә ТР Дәүләт алкоголь инспекциясе 5605 мөрәҗәгатьне караган, шуның 85,1 проценты — сәүдә өлкәсенә, 10,4 проценты – көнкүреш, 0,7 проценты – торак-коммуналь, калган 4 процентка якыны элемтә, җәмәгать тукլануы, транспорт, белем бирү, медицина хезмәтләренә туры килә. Аларның һәммәсен ике якның ризалыгы белән хәл итү мөмкин дә түгел. Быел кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча 16 суд утырышы үткәрелгән инде. 11 кулланучының мөрәҗәгате (тулысынча яки өлешчә) 235,66 мең сумга канәгатьләндерелгән.

НИ ӨЧЕН МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘЛӘР?

Моның төп биш сәбәбе бар: сыйфатсыз товарлар (кесә телефоннары, суыткычлар, өс, аяк киемнәре) сату, тиешенчә башкарылмаган (күрсәтелмәгән) эш яки хезмәт, товар яки хезмәт турында тулы яисә дөрес булмаган мәгълүмат бирү, дәгъваны карау вакытын бозу, кимчелекләр табылган очракта кулланучының таләпләрен үтәүдән баш тарту.

КАЯ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ?

- Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе – **8(843) 278 92 00, 278 91 92.**
- Кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе – кайнар линия телефоны – **8(843) 23694 11.**
- «Татарстан Республикасы гигиена һәм эпидемиология үзәге» кулланучыларга консультация бирү үзәге – **8(843) 221 90 16.**

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары	Адресы	Телефоны
Әлмәт (Әлмәт, Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Ютазы районнары)	423400, Әлмәт шәһәре, Гафиятуллин ур., 26	(8553) 22-21-33
Арча (Арча, Әтнә, Балтач, Кукмара, Саба, Теләче районнары)	422000, Арча шәһәре, Банк ур., 2а	(84366) 3-28-93
Яшел Үзән (Яшел Үзән, Апас, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш районнары)	422250, Яшел Үзән шәһәре, Засорин ур., 9	(84371) 4-58-78
Казан (Казан шәһәре, Биектау, Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнары)	420107, Казан шәһәре, Һади Такташ ур., 94	(843) 277-94-96
Чаллы (Чаллы шәһәре, Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Мамадыш, Минзәлә, Менделеевск, Тукай районнары)	423802, Чаллы шәһәре, Корчагин ур., 2а (10/34а комплексы)	(8552) 71-43-03
Түбән Кама (Түбән Кама, Аксубай, Зәй, Мөслим, Сарман, Чирмешән районнары)	423570, Түбән Кама шәһәре, Бызов ур., 20а	(8555) 36-63-76
Чистай (Чистай, Алексеевск, Әлки, Яңа Чишмә, Нурлат, Спас районнары)	422950, Чистай шәһәре, Бебель ур., 121д	(84342) 5-49-85

ИНТЕРНЕТТАН ТОВАР САТЫП АЛУНЫҢ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫН НИЧЕК КАЙГЫРТЫРГА?

1. Нәрсәгә игътибар итәргә: социаль челтәрләр һәм форумнардагы фикерләргә. Сатучының репутациясе нинди? Ул үз вазифаларын намус белән һәм вакытында башкарамы?

2. Интернет-кибет сайтында сатучының исеме (әгәр ул шәхси эшкуар икән), адресы турында мәгълүмат булырга тиеш.

3. Кибетнең банк карталары белән ничек эшләвенә игътибар итегез. Намуссыз сатучылар банк хисабы аша түләүләрне яратмый, чөнки аларга банк аркылы протест белдерергә мөмкин.

4. Товарның тасвирламасы. Сатучы аның турындагы төп мәгълүматларны җиткерергә тиеш: куллану үзлекләре, эшләнгән урыны, бәясе, хезмәт итү вакыты, яраклылыгы һәм гарантия вакыты. Товарны китергәндә сезгә тагын да күбрәк мәгълүмат биреләчәк. Сатучы товарны куллану кагыйдәләре белән таныштырырга бурычлы.

5. Товар туры килми икән, аны ничек кире кайтарырга? Теләсә кайсы сатып алучы китергән вакыттан алып 7 көн дәвамында товарны интернет аша кире кайтарырга хокуклы. Шунысын да искәртик: сезгә товарны сатучыга илтеп бирү чыгымнарын капларга туры киләчәк. Әмма товарны сатып алудан баш тарту турында хәбәр иткәннән соң ун көн үткәч, түләнгән акча кире кайтарылырга тиеш.

6. Товарны инде берничә ай кулланасыз, ә кимчелекләрен хәзер генә таптыгызмы? Аның бәясен киметү, алыштыру яки түләнгән акчаны кире кайтаруны таләп итә аласыз. Кире кайтарган чагында товарны китерү чыгымнарын сатучы күтәрә. Гарантия срогы турында: әгәр аның вакыты чыкмаган икән, таләпләрегезне кыю рәвештә белдерегез. Әгәр срогы ачыкланмаса, таләпләр товарны сатып алганнан соң ике ел эчендә җиткерелергә мөмкин.

КИҢӘШ

Кунакханәдә яшәү: без күпме түләргә тиеш

Җәйге сезон башланды дияргә була, ә кунакханәгә урнашканда һәм аннан киткәндә ниләр эшләргә икәнлеген бөтен кеше дә белми. Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе нәрсәләргә игътибар итәргә кирәклеген искәртә.

- Исәп-хисап ясаганда сезгә касса чегы яки документ бирәләр.
- Яшәгән өчен түләүне исәп-хисап сәгате нигезендә алалар, аны кунакханә мөстәкыйль рәвештә билгели. Әгәр номерда тоткарлангансыз һәм исәп-хисап сәгатеннән соң да яшәп калгансыз икән, түләү кунакханә билгеләгән тәртиптә алына.
- Исәп-хисап сәгатенә карата шактый сораулар да туа. Кунакханәгә урнашу һәм кулланучының аннан китүе җирле вакыт буенча агымдагы тәүлекнең 12 сәгатендә билгеләнгән исәп-хисап сәгатенә карап башкарыла. Кунакханә җирле һәм эшчәнлек үзенчәлекләрен исәпкә алып, билгеләнгән исәп-хисап сәгатен үзгәртергә хокуклы.
- Номерга урнашу вакыты башкаручы, ягъни кунакханә тарафыннан билгеләнә. Кулланучының номердан китү һәм анда урнашу вакыты арасындагы аерма ике сәгатьтән дә артмаска тиеш.
- Әгәр кунакханәгә исәп-хисап сәгатенә кадәр 00.00 сәгатьтән урнашкансыз икән, түләүне ярты тәүлек бәясеннән артмаган күләмдә алырга кирәк.
- Кунакханә, үз чиратында, яшәгән өчен тәүлекләп яки сәгатьләп түләүне билгеләргә хокуклы.
- Сезнең һәм кунакханә арасында төзелгән килешүне үтәүдән теләсә кайсы вакытта баш тарта аласыз.
- Кунакханә сезнең ризалыктан башка номер бәясенә кермәгән башка түләүле хезмәтләр тәкъдим итә алмый.

Кунакханәгә урнашкач та, сез чикләнмәгән хокуклардан файдалана алачаксыз дигән сүз түгел әле. Мисал өчен, кунакханә күрсәтелгән көнгә буш номерлар булмаган очракта, броньлау мөмкинлеге бирмәскә хокуклы. Шулай ук башкаручы, ягъни кунакханә, барлык кулланучылар өчен дә бертөрле максималь яшәү вакытын билгели ала.

Микродулкынлы мич зәхмәте

Микродулкынлы мич бүген һәркемдә диярлек бардыр. Аны немец галимнәре уйлап тапкан. Максаты – ризыкны тиз арада җылыту һәм немец солдатлары казармаларына салкын вакытта җылылык бирү. Шуны куллана башлаганнан соң, хәрбиләр сәламәтлекләреннән зарлана башлаганнар. Шуннан соң немецлар бу мичләрдән баш тарта.

Швейцария, Россия һәм Германиядә үткәрелгән фәнни тикшеренүләр һәм клиник сынауларның нәтиҗәләре күрсәткәнчә, микродулкынлы мичләр баш миенә, ашказанына, ашкайнату системасына зыянлы икән. Анда җылытылган ризыкны еш кулланганда, ирләрнең һәм хатын-кызларның җенси гормоннар эшләп чыгару сәләте үзгәрә. СВЧ-мичләрдә әзерләнгән ризыкта кирәкле витаминнар, минераллар һәм файдалы матдәләр юкка чыга. Яшелчәләрдәге минераллар, җылытканда, канцероген матдәләргә әверелә. Аннан чыккан ашамлыклар ашказанында, эчәклекләрдә яман шеш барлыкка китерергә мөмкин, еш кулланганда, хәтер начарлана, интеллект түбәнәя, дигән фикер дә бар.

СВЧ-мичләренең ишеге янындагы ярыклардан күпләп нурланыш чыга, шуңа күрә аның каршысында тору бигрәк тә балаларга һәм көмәнле хатын-кызларга гаять зарарлы икән. Галимнәр фикеренчә, бу мичләрнең тискәре тәэсире бары 12-15 ел үткәч кенә сизелә башлый.

Нияз БИШБАЛТА, Казан.

АФИША
29 МАЙ-4 ИЮНЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

29 май «Ричард III» (У. Шекспир)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум

30 май «Агыла да болыт агыла...» (Х.Туфан, Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 300-350 сум

А.Пушкин исемендәге Россия дәүләт академия драма театры
30 май «Ревизор» (Н.Гоголь)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 500-2500 сум

КДМИ студентларының диплом эше
30 май «Иярәр» (Ә. Фәтхетдин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 100 сум

А.Пушкин исемендәге Россия дәүләт академия драма театры
31 май «Ревизор» (Н.Гоголь)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 500-2500 сум

2 июнь «Женитьба» (Н.Гоголь)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 500-2500 сум

3 июнь «Женитьба» (Н.Гоголь)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 500-2500 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА һӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

29 май «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова)
Башлана: 18.30

30 май «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30

31 май «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 18.30

1 июнь «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
Башлана: 18.30

1 июнь «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 300-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

1 июнь «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00

2 июнь «Идет Коза рогатая» (М.Протасова)
Башлана: 11.00

3 июнь «Хаврошечка» (Л.Савчук)
Башлана: 11.00, 13.00

4 июнь «Колобок маҗаралары» (Л.Кожевников)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 200-300 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

29 май Хәния Фәрхи концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1200 сум

30 май Хәния Фәрхи концерты
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1200 сум

МЕГА СӘҮДӘ ҮЗӘГЕ
(ҖИҢҮ ПРОСПЕКТЫ, 141)

3 июнь «Яшел фитнес»
Башлана: 18.00

4 июнь «Яшел фитнес»
Башлана: 10.00
Керү ирекле

ГОРЬКИЙ-ӘМӘТ УРМАН-ПАРКЫ
(ҖИҢҮ ПРОСПЕКТЫ, 69)

3 июнь «SuperFest» буяу фестивале
Башлана: 16.00
Билет бәсе: 100 сум

ҖИҢҮ ПАРКЫ

1 июнь Пульт белән идарә ителүче уенчык машиналар ярышы
Башлана: 15.00
Керү ирекле

ПЕТЕРБУРГ ҖӘЯҮЛЕЛӘР УРАМЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 11)

2 июнь Халыкара Европа музыкасы фестивале ачылышы
Башлана: 14.00
Керү ирекле

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

Конфедерация Кубогы – нәрсәгә әзер булырга?

Тина КАНДЕЛАКИ, Матч-ТВ генераль продюсеры:

Әле бер генә Россия телеканалы да Дөнья чемпионаты һәм Конфедерация Кубогын трансляцияләү өчен рөхсәт алмады. Ләкин без бу өлкәдә эшлибез. Ниндидер өмет чаткысы күренә инде. Ә Кубок узган шәһәрләр, шул исәптән Казан турында без инде материал әзерләдек. Республика җитәкчеләренә рәхмәт сүзләре җиткерәсем килә. Аеруча да Илсур Метшинга (Казан мэры). Шәһәргә кагылышлы бер сорауга да ул «юк» дип җавап бирми. Әлбәттә, Казанда узачак Конфедерация Кубогыннан да трансляция алып барачакбыз.

Казанда узачак Конфедерация Кубогының якынча ничегрәк узасын 17 май көнне күзәтә алдык инде. Шулай да кайбер кагыйдәләрне янәдән искәртеп китсәк, зыян булмас.

«СОҢГЫ МИЛЬ» НӘРСӘ УЛ? Матч буласы көнне «Казан-Арена» стадионы территориясе транспорт хәрәкәте өчен тулысынча ябылачак. Шулай итеп, Чистай, С.Хәким, Ямашев проспекты, Гаврилов, Арбузов урамнарыннан инде узып булмаячак. Юл йөрешен чикләүләре тулысынча күрсәтелгән карта якын-тирәдә махсус сайтта барлыкка киләчәк. Бу чикләүләр стадион янында яшәүче кешеләргә кыенлык тудырырга мөмкин. Ләкин республиканың яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов белдергәнчә, үз йортларына керү өчен аерым юллар булдырганнар. Өйгә кайту өчен бер кешегә дә аерым документлар тутырырга кирәк түгел.

БУШЛАЙ ТРАНСПОРТ. Матчка билетлары булган кешеләр җәмәгать транспорты һәм электричкадан бушлай файдалана ала. Ә стадионга тамашачылар «җанатар паспорты» белән керәчәк. Бу паспорт һәм билет ярдәмендә футбол матчлары узачак Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи шәһәрләренә дә бушлай барып була. Димәк, футбол – менә дигән сәяхәт итү чарасы да. Казанга исә 40 процент тамашачы шәхси транспортында киләчәк. Алар өчен шәһәр хакимияте өстәмә машина кую урыннары әзерли.

«Җанатар паспорты» – стадионга утырган һәр кешенең иминлеге ул. Биредә җанатар турында барлык мәгълүмат тупланган. Бу исә стадиондагы куркынычсызлыкны берничә тапкыр арттыра.

МИТИНГЛАР ТЫЕЛА. 18, 22, 24, 28 июнь көннәрендә Казанда Конфедерация Кубогы үтә. Футбол матчына әле бер ай вакыт бар. Шулай да инде 1 июньнән шәһәр халкы «чикле режимда» яшәячәк. Бу көннән 12сенә кадәр урамда Кубокка һәм Футбол буенча дөнья чемпионатына бәйле булмаган митинг, җыелыш, демонстрация, пикетлар ике сәгать вакыттан артык барырга тиеш түгел. Анда катнашкан кеше саны 150дән артмау шарт. Митингларны Дәрвишләр бистәсендә, Сәетгалиев исемендәге мәдәният сарае каршында һәм Юдинода гына уздырырга рөхсәт ителгән.

«Ясалган экватор»

26-31 май көннәрендә Татарстанның милли музеенда «Ясалган экватор» дип аталган арт-проект тәкъдим ителә. Анда Россия, Словакия, Белоруссия, Украина, Исландия, Франция, Швейцария рәссамнарының эшләре тәкъдим ителә.

2008 елда Словакиядә старт алган әлеге проектка 2013 елда Россия дә кушылды. Беренчеләрдән булып аны Саратов өлкәсе кабул итте.

Проект кысаларында 40075 картинадан (үлчәме 20х20 см) символик чылбыр «үреп», Җир шарын «колачлап алу» күздә тотыла. 40075 саны очраклы түгел – җир экваторы шуның кадәр километр тәшкил итә. Әлеге чылбыр исә дөнья халыклары арасындагы дуслык һәм аңлашуның мөһимлеген аңлата.

«Ясалган экватор» арт-проектыннан кала, Милли музейда Словакиянең мәшһүр рәссамы – Мәскәү Халыкара мәдәният һәм сәнгать академиясе академигы, Сальвадор Дали исемендәге дөнья премиясе лауреаты, проект авторы Андрей Смолакның эшләре белән дә танышырга мөмкин булачак. Ачылыш бүген 15.30 сәгатьтә.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1646. Гомуми тираж – 6043.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 717. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы